Министерство образования и науки Российской Федерации
**Нижнекамский химико-технологический институт (филиал)**
Федерального государственного бюджетного образовательного учреждения высшего профессионального образования
«Казанский национальный исследовательский технологический университет»

# ТАТАРСКИЙ ЯЗЫК. КУЛЬТУРА РЕЧИ

УЧЕБНО-МЕТОДИЧЕКОЕ ПОСОБИЕ

**Нижнекамск**
**2013**

**УДК 811.512.145**
**З-26**

Печатается по решению редакционно-издательского совета Нижнекамского химико-технологического института (филиала) ФГБОУ ВПО «КНИТУ».

**Рецензенты:**
**Маркова Н.Г.,** доктор педагогических наук;
**Саримова Р.Р.,** кандидат педагогических наук, доцент.

**Зарипова, Г.Г.**
**З-26** Татарский язык. Культура речи : учебно-методическое пособие / Г.Г. Зарипова, Б.М. Мирдиянова. – Нижнекамск : Нижнекамский химико-технологический институт (филиал) ФГБОУ ВПО «КНИТУ», 2013. – 60 с.

Составлено с учетом требований к преподаванию татарского языка в высших учебных заведениях. Способствует развитию творческих способностей студентов, усвоению языковых знаний, привитию умений и навыков письменного выражения мыслей на татарском языке.

Предназначено для студентов всех форм обучения.

Подготовлено на кафедре иностранных языков (цикл русского и татарского языков).

**УДК 811.512.145**

© Зарипова Г.Г., Мирдиянова Б.М., 2013
©Нижнекамский химико-технологический институт (филиал) ФГБОУ ВПО «КНИТУ», 2013

## ЛЕКСИКА ҺӘМ ЛЕКСИКОЛОГИЯ

Лексика грек телендәге *лексикос* сүзеннән килеп чыккан һәм телнең сүзлеге, сүзлек составы дигән мәгънәләрне аңлата. Билгеле бер телдә булган сүзләрнең һәм әйтелмәләрнең бөтенесе бергә шул телнең сүзлек составын тәшкил итә. Аерым язучы, әсәр, кеше телендәге сүзләрне дә лексика дип йөртү бар.

Лексика һәм лексикология дигән терминнарны бутарга ярамый. Лексика — ул телнең сүзлек хәзинәсе, ә лексикология — лексиканы өйрәтә торган фән; соңгысы термин буларак грекча *«лексикос»* (сүзлек) һәм *«логос»* (фән) сүзләреннән алынган.

Лексикология грамматика, фонетика, тел тарихы һәм стилистика белән беррәттән, философия, психология, тарих фәннәре белән дә тыгыз бәйләнгән.

Лексикологиянең бер тармагы — семасиология (яки — семантика). Ул термин буларак грек теленнән кергән, *семасия* (мәгънә) һәм *логос* (фән) дигән сүзләрдән төзелгән һәм, фән буларак, сүзнең мәгънәсен өйрәнә. «Сүзнең мәгънәсе»нә сүзләрнең күпмәгънәлелеге, омонимия мәсьәләләре, синонимнар һәм антонимнар, эмоциональ-экспрессив сүзләр, парлы сүзләр, фразеологик әйтелмәләр керә.

Лексикологиядә сүзләрнең актив һәм пассив кулланылышы, сүзлек составының чыганаклары, үсеш, үзгәреш проблемалары, сүзләрнең, килеп чыгышы, стилистик үзенчәлекләре тикшерелә.

Сүзлекләр турындагы фән лексикография дип атала. Лексикография дә лексикология белән тыгыз бәйләнгән.

## СҮЗ ҺӘМ АНЫҢ АСЫЛ СЫЙФАТЛАРЫ

Сүзнең мәгънәсе дип аның чынбарлыктагы билгеле бер күренешләр белән бәйләнешенә, мөнәсәбәтенә әйтәбез.

*Сүз* ул сөйләмдә мөстәкыйль берәмлек буларак кулланыла ала торган мәгънәле аваз яки авазлар комплексы.

Сүз — телнең төп элементы. Сүзләрдән *сузтезмәләрдән,* ә

сүзтезмәләрдән *җөмләләр* төзелә. Җөмләләр ярдәмендә кешеләр үзара аңлашалар, аралашалар.

Кеше сүз ярдәмендә предметны, күренешне, аларның үзенчәлекләрен һ. б. атый. Шуңа күрә сүзнең *ату сәләте,* ягъни номинатив функциясе аның төп сыйфаты итеп танылa. Күпчелек сүзләр предметларга, аларның билгеләренә, хәрәкәтләргә атама бирә. Мәсәлән: *йорт, агач, таш, юл, иске, яңа, биек, зирәк, йөрү, кайту, яшәү.*

Сүзнең номинатив функциясе предметларны атаганда бик ачык чагыла, чөнки аларны күреп тә, тотып карап та була: *китап, каләм, тәрәзә, сыер, сарык, карга, сыерчык, чебен, су, щир, туфрак, ай, кояш, йолдыз.* Ләкин сүз күрергә һәм тотып карарга мөмкин булмаган предметларны, күренешләрне, билгеләрне дә атый: *уй, акыл, белем, шик, надан, батырлык, горурлык, көч, иреклек, хөрмәт.*

Барлык сүзләр дә төшенчәләрнең атамалары була алмый. Мәсәлән, бәйлекләр, теркәгечләр, кисәкчәләр, ымлыклар, алмашлыклар, ялгызлык исемнәре гадәттә төшенчәләрне атамыйлар.

## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ КҮПМӘГЪНӘЛЕ СҮЗЛӘР

Дөньядагы бөтен телләргә дә сүзләрнең күпмәгънәлеле-ге хас. Ләкин шул ук вакытта һәр телдә бер генә мәгънәне аңлатучы сүзләр дә була. Конкрет бер мәгънәгә генә ия булган сүзләрне термин дип атыйлар: водород, электр кыры, фонема, җөмлә, ракета, мелиорация.

Сүзнең ике яки аннан да артык мәгънәне белдерүе *күп-мәгънәлелек* дип атала. Күп мәгънәлелек сүзнең предметларны (күренешләрне) гомумиләштерә алу үзенчәлегенә бәйләнгән.

Күчерелмә мәгънә берәр төрле яклары белән охшаш предметларны, күренешләрне бер-берләренә абстракт ча-гыштырудан туа. Мәсәлән, «үсемлек *тамыры»* — «сүз *га-мыры», «кан тамыры»;* «кеше *юлдашы»* — «җир *юлдашы*»; «кеше *култыгы*» — «диңгез *култыгы»;* «кеше *йөзе»*— «җир *йөзе»;* «кеше *башы»* — «эш *башы»,* «сүз *башы»;* «кар *ява»*—

«сүз *ява»;* «бала *елый»* — *«*диңгез *елый»;* «учак *яна*» — «йөрәк *яна*»; «утын *кисү»* — «юл *кисү*».

Сүзнең күчерелмә (өстәмә) мәгънәләре сөйләмне җайландыруда һәм гомумән «образлы тел» тудыруда әһәмиятле роль уйный:

1) *тоту* сүзеннән: *кулдан тоту, кар тоту, ачу тоту, истә тоту, сак астында тоту, очкылык тоту, сүзне кыска тоту, үзүзеңне тоту, балык тоту, бизгәк тоту, күз алдында тоту, киңәш тоту, киртә тоту, шик тоту, юл тоту;*

2) *салу* сүзеннән: *йорт салу, юл салу, су салу, тоз салу, ямаулык, салу, оеткы салу, баш салу, өс киемен салу, нигез салу, күз салу, йөрәккә салу, хәтергә салу, баш астына мендәр салу, аш салу, хат салу, суга салу;*

3) *каты* сүзеннән: *каты агач, каты су, каты кул, каты күңел, каты суык, каты буран, каты көрәш, каты юл, каты сүз, каты колак, каты күз, каты борын, каты яңгыр, каты җил, каты сөйләү, каты елау.*

Димәк, сүзнең күттмәгънәлелеге дигәннән аның үзалдына торганда түгел, ә бәлки төрле сүзтезмә-ләрдә күп мәгънә белдерүен аңларга кирәк.

Күпмәгънәлелекнең асылы шуннан гыйбарәт: объектив чынбарлыктагы бер предметның яки күренешнең атамасы икенче предметка яки күренешкә күчерелә, анда бер сүз бер үк вакытта берничә предметның (күренешнең) атамасы булып әверелә, ул берьюлы берничә предметка, күренешкә «хезмәт итә».

'Татар телендә күпмәгънәле сүзләр өч төрле була: метафора, метонимия, синекдоха.

Метафора — күпмәгънәлелекнең иң күп таралган һәм продуктив төре. Әгәр дә предметлар (күренешләр) бер берләренә кайсы яклары белән булса да охшасалар, еш кына бер үк сүз белән белдереләләр. Метафора ул бер предметның (күренешнең) атамасын билге, төс, форма, функция охшашлыгы нигезендә икенче предметка (күренешкә) кушу, күчерү дигән сүз: тегү *энәсе* — ылыслы агач *энәсе,* баш *түбәсе* — өй *түбәсе,* хайван *коерыгы* — самолет, поезд, колонна *койрыгы, җылы* көн

— *җылы* караш, *кара* балчык — *кара* көннәр — *кара* фикерләр, *алтын* йөзек— *алтын* күз — *алтын* вакыт — *алтын* сүз — *алтын* кеше.

Метонимиягә ачык мисал итеп, предметларның лространство уртаклыгына нигезләнгән төрен күрсәтергә була. Чыннан да, ике предметның берсе икенчесенә урнаштырылган булса, аларны атау өчен бер генә сүз кулланыла:

«Зал тыңлады,
*Зал* тын.»
«Кинәт
Ул ашыгып кулын күтәрде дә
*Зал* өстенә күзен төбәде,
Көне-төне тырышып эшләгәнен
Ул әйтергә *залга* теләде».

*(Һ. Такташ)*

Метонимия татар телендә, нигездә, *исем* сүз төркеменә хас.

Синекдоханың асылы шуннан гыйбарәт: бер үк сүз бөтеннең атамасы булып та, шул бөтеннең өлешем белдерү өчен дә кулланыла. Мәсәлән, *баш, күз, авыз, тел, кул* сүзләре тәннең өлешләре саналалар *(баш авырта, күз кара-шы, авыз чайкау, гел ачылу, кул бирү).* Ләкин алар синекдоха буларак *кеше* мәгънәсендә дә (бөтеннең атамасы урынында өлешнең атамасы) йөртелә алалар: *Яңа килгән, баш* (кеше) *яхшы булып чыкты. Бу күз* (кеше) *күпне күрүчәнрәк. Безнең семьяга тагын бер авыз* (кеше) *өстәлде. Ул разведкадан тел беләк* (кеше белән) *кайтты. Мин хуҗаның уң кулын* (ышанычлы кешесен) *күрдем.*

## ОМОНИМНАР

### Омонимнар хакында төшенчә

Әйтелешләре бертөрле, ә мәгънәләре төрле булган сүзләр *омонимнар* дип атала: *төш* - сон, *төш* - место, *төш* – полдень, *төш* – шарообразное мелкое мучное национальное кушанье, *төш* – ядро (чикләвек төше – ядро ореха), *төш* – выходи (из трамвая).

Хәзерге татар теле омонимнарга бик бай.

**Омонимнарны төркемләү.** Татар телендәге омонимны ясалышлары, лекснк-семантик һәм грамматик мәгънәләре әйтелеш һәм язылыш үзенчәлекләре буенча берничә төркемгә бүленә.

Ясалышлары буенча татар телендәге омонимнар түбәндәгечә төркемләнә:

1) **Төп омонимнар:** *ач* - голодный, *ач* - открой; *көл* - зола, *көл* - смейся; *күн* - кожа выделенная, *күн* - соглашайся; *көй* - мелодия, *көй* - горюй; *уй* - дума, *уй* - вырежь; *яз* - весна, *яз* - пиши. Төп омонимнар гадәттә тамыр сүзләрдән тора һәм бер иҗекле була.

2) **Ясалма омонимнар:** *ата* - отец, *ата* - стреляет; *алма* - яблоко, *алма* - не бери, *батыр* - герой, *батыр* - топи; карга - ворона, карга - в снег (провалиться); *саулык* - ягненок, *саулык* - здоровье; туган — родня, *туган* - родился, *урам* — улица, *урам* — жну. Ясалма омонимнарның берсе тамыр, ә икенчесе кушымчалы була, күбрәк ике иҗектән тора.

**Әйтелеш-язылыш үзенчәлекләре** буенча татар телендә омонимнар дүрт төрле:

1. *Саф омонимнар.* Саф омонимнарга гадәттә лексик омонимнар керә, алар теге яки бу грамматик формаларны алганда да, нигездә, бер-берләренә омоним булып калалар: *ат* — лошадь (аты, атлар, атны), *ат*—имя (аты, атлар, атны); *сыз* — черти (сызыгыз, сызсыннар), сыз —уходн (сызыгыз, сызсыннар); *без* — шило (безне), *без* — мы (безне).

2. *Омофоннар.* Омофоннар дип язылышлары төрлечәрәк булган омонимнарга әйтәләр *сылу* (сыйфат) һәм *Сылу* (ялгызлык исеме), *искеру* һәм *ис керү, аталу* һәм *ат алу, чигенә* һәм *чи генә, болынны* (төшем килешендәге исем) һәм *болынны(лы)* – сыйфат.

3. *Омоформалар.* Омоформаларда бер сүз төркеменнән булган сүзләрнең аерым формаларына икенче сүз төркеменнән булган сүзләрнең аерым формалары туры килә: *булмә* — комната (исем, баш килештә, берлектә), *булмә* - не дели (боерык фигыль, юклыкта); *суга* (исем, юнәлеш килешендә), *суга* (хикәя фигыль, хәзерге заманда, берлектә, 3 нче затта).

4. *Омографлар.* Болар — бер үк төрле язылып та, басымнары аркасында төрлечәрәк әйтелә торган омоним сүзләр: *аерма* (исем) һәм *аерма* (фигыль), *басма* (исем) һәм *басма* (фигыль), *торма* (исем) һәм *торма* (фигыль).

Биремнәр.

1. Түбәндәге татар сүзләренә омоним булган рус сүзләрен әйтегез.

**Тара, туз, тир, май, карта, бар, бас, таз, тире, тур.**

2. Бу сүзләрнең башка мәгънәләрен һәм омонимнарын, җөмләләр төзеп, табыгыз.

**Яра, йөз, алма, ат, кер, саф, яшь, сабак, як, кара.**

3. Бу сүзләргә аваздаш сүзләр табып, һәр ике сүзнең мәгънәләрен сүзтезмәләр өстендә аңлатып бирегез.

| | | |
|---|---|---|
| Көзге | Баш | Сынау |
| Яшь | Ярма | Сабак |
| Без | Туп | Парлы |
| Яз | Үпкә | Ял |
| Кала | Буын | Табак |
| Кичә | Бал | Ябык |
| Ат | Җәймә | Җилле |
| Якты | Атлы | Чабу |
| Ал | Туры | Сырт |
| Җәй | Көтү | Басма |

## СИНОНИМНАР

### Синонимнар турында төшенчә

Синонимнар дип мәгънәләре тәңгәл яш бер-беренә якын торган сүзләргә әйтәләр.

Синонимнарга мисаллар: *зур* - *олы* - *өлкән* - *дәү* - *эре, көч* - *куәт* - *гайрәт* - *кодрәт* - *егәр* - *дәрман, сәламәтлек* - *саулык* - *исәнлек* - *тазалык* - *сихәтлек, ях шы* - *һәйбәт* - *шәп* - *ару, яшәү* - *тору* - *гомер итү* - *көн күрү, үтенү* - *ялыну -ялвару* - *инәлү, ярату* - *сөю* - *мәхәббәт* - *гыйшык, элү* - *тагу* - *асу, хакыйкать* -

*дөреслек - чынлык - хаклык, сукыр - күзсез, рәт - саф, оят - гарьлек - хурлык, кечкенә - бәләкәй - вак - нәни, кебек - күк - шикелле, тиң-тик - төсле - сыман -* сымак *- ише, аңлау - төшенү, үткән ел - былтыр, читен - кыен - авыр, түзү - чыдау - сабыр итү.*

Синонимнар группасы **синонимик рәт** дип атала: *гасыр – йөз* (бер синонимик рәт була), *әлбәттә - һичшиксез – шөбхәсез – икеләнүсез – шиксез* (икенче синонимик рәт), *матур - гүзәл – чибәр – күркәм – күрекле – ямьле – нәфис – сылу* (өченче синонимик рәт) һ.б.

Биремнәр.

1. Түбәндәге сүзләрнең синонимнарын табып язарга:

**Абруй, авария, азак, адашу, ашамлык, әлифба, апатия, аргумент, акыл керү, алдау, аңлаешлы, арту, ару, атаклы, авырту, ашыгу.**

2. Түбәндәге сүзләрнең синонимнарын табыгыз, шул синонимнарны кертеп, җөмләләр төзегез:

**Боерык, авторитет, бур, болын, сынау, сөйләшү, бәхетсезлек, күзсез, суык, җылы, очкын, чөй.**

3. Парлы сүзләрнең синонимнарын табып, сүзне тәмамлап язарга, җөмләләр төзергә:

**Кадер-..., шау-..., хәер-..., ким-..., ару-..., әүвәл-..., әйләнү-..., ярым-..., рәхим-..., шик-..., абына-..., чит-..., бата-...**

## АНТОНИМНАР

Антонимнар — алар капма-каршы мәгънәдәге сүзләр: *зур - кечкенә, югары - түбән, яхшы - начар, каты – йомшак, карт - яшь, күп - аз, озын - кыска, дөрес – ялган.*

Антонимнарга халык мәкальләре, әйтемнәр, табышмаклар бай. Мисаллар: *Күңел - **куркак**, кул - **батыр**. **Эшләгән** үлмәс, **эшләмәгән** көн күрмәс. **Эш башында** мактанма, **эш беткәндә** мактан. **Аз** сөйлә, **күп** эшлә. **Каты** агачны **йомшак** корт ашар. **Яхшы** сүз - җан азыгы, **яман** сүз - үлем казыгы. Замананы **хурлыйбыз**, үтеп киткәч **мактыйбыз**. **Үлгән** лачыннан **тере** карчыга артык. Кәҗә үзе **чыдам түгел**, күне **чыдам.***

Антоним сүзләр парлы сүзләр ясауда да база булып торалар: *ачлы-туклы, юк-бар, аллы-артлы, ак-кара,килделе-киттеле, кайта-китә.*

Телдә бер сүзгә берничә сүз антоним була ала: ***калын*** сүзенә ***юка***, ***нечкә, аз*** сүзенә ***күп, мул, яхшы*** *сүзенә* ***начар, яман, әшәке*** һ.б. сүзләр антоним була.

Төзелешләре ягыннан антонимнар өч төрле була:

1) **Төп антонимнар:** *яз - көз, кыш - җәй, ак - кара, уң - сул, кер - чык, ал - бир, бар - юк.* Төп антонимнар тамыр сүзлшәрдән торалар.

2) **Ясалма антонимнар:** *караңгы - якты, аркылыга - буйга, тыныч - хәвефле, кыйммәт - очсыз, байлык – ярлылык, анда – монда, ямьле – ямьсез, матур – матур түгел.*

3) **Антоним парлы сүзләр:** *барыр-бармас - килер-килмәс, ызгыш-талаш - дуслык-татулык.*

Лексик мәгънәләре ягымнан антонимнарны 4 төргә бүлергә мөмкин:

1) Предметларның (күренешләрнең) озынлык – күләм үлчәмен белдерүче антонимнар: *озын - кыска, тар - киң, якын - ерак, артык - ким, югары - түбән.*

2) Вакыт төшенчәсен белдерүче антонимнар: *кич - иртә, көн – төн, быел - былтыр, бүген - кичә, элек - хәзер.*

3) Кешеләргә, предметларга характерлы сыйфатларны тасвирлаучы антонимнар: *пычрак - чиста, ачы - төче, батыр - куркак, саран - юмарт, әдәпле - дорфа, эшчән - ялкау, таза - ябык, яшь - карт, каты - йомшак.*

4) Табигать күренешләрен белдерүче антонимнар: *җылы - салкын, аяз - болытлы, җир - су, тирән - сай, коры - юеш, кар - яңгыр.*

Биремнәр.

1. Түбәндәге сүзләрнең антонимнарын, шул антонимнарның синонимнарын табып язарга.

**1) мактау –**

**2) туры –**

**3) юмарт –**

**4) авыру –**

**5) зарлану –**

**6) шатлык –**

**7) куркак –**

2. Парлы сүзләрнең антоним булган икенче өлешен табып язарга, җөмләләр төзергә:

**Баш-..., ята - ..., асты - ..., кичәле - ..., караңгылы - ..., кереп - ...., көн - ..., иртә - ...., ишекле - ...., эсселе - ...., чиле -....**

3. Мәкальләрнең антоним сүз кергән икенче өлешен язып бетерергә:

**1) Өең кысан булса да, күңелең ... ... . 2) Олы өйгә ни кирәк, кече өйгә ... ... . 3) Җәен актан киен, кышын ... ... . 4) Ялгыз ял күрмәс, күмәк ... ... . 5) Яхшы тел – яз кебек, яман тел - ... ... . 6) Батыр даны ил телендә, ... уе гел үлемдә. 7) Картлар сүзен капчыкка сал, ... сүзен янчыкка сал. 8) Туры әйткән котылган, ... ... . 9) Күп сүзнең ... яхшы. 10) Сөйдергән дә - тел, ... ... ... .**

4. Түбәндәге сүзләрнең антонимнарын табарга, антоним парларны кертер җөмләләр төзергә:

**Җыйнак, җиңел, әкрен, яшьлек, юан, юаш, шатлык, шапшак, хәерче, тәмле, тыгыз, талантлы, пешкән, оптимизм, кыйммәт, караңгы, киендерү, карт, йомшак.**

## ФРАЗЕОЛОГИЯ

**Фразеология һәм аның өйрәнү предметы.** Татар теленең фразеологик фонды бай һәм күпкырлы. Ул сөйләмен баетуда, утемлерәк, көчлерәк һәм үткенрәк итүдә, художестволы әсәр стиленә сәнгатьлелек бирүдә, фикерне тулырак ачуда әһәмиятле роль уйный. Шуңа күрә фразеологиянең, башлыча, мәктәп практикасы белән турыдан-туры бәйләнеше бар. Чыннан да, аннан башка мәктәптә яшь буынга тел өйрәтүне, тел культурасын җәелдерүне күз алдына китерүе дә авыр. Икенчедән, фразеологик материал язучы телендә алтын фонд санала. Аннан оста файдалана белү — язучы-художник әсәренең уңышлы һәм отышлы ягы: автор образларны, вакыйгаларны сиземлерәк итеп сурәтли, аларга үзенчәлекле төс кертә, әсәр

теленең халыкчанлыгын, гадилеген, аһәңле яңгырашын тәэмин итә. Өченчедән, телнең фразеологик байлыгын, аның төзелешен, семантикасын (мәгънәсен) яхшы белү тәрҗемә эшендә бик тә кирәк.

Биремнәр.

1. Түбәндәге фразеологизмнарның мәгънәләрен аңлатыгыз:

**1) Иске авыздан яңа сүз. 2) Ат казану. 3) Исеме чыгу. 4) Искә төшерү. 5) Мөгез чыгару. 6) Күз бәйләнү. 7) Авызына су кабу. 8) Аяк сузу. 9) Авыз пешү. 10) Баш ию. 11) Колакка салу. 12) Кул селтәү. 13) Тел төбе.**

2. Рус телендә бирелгән фразеологизмнарның татар телендә кулланылышын табып язарга:

**Беречь как зеницу ока, бездонная бочка, взять в руки, волосы встают дыбом, взорваться как порох, отвечать головой, бросать слова на ветер, гнаться за двумя зайцами, впитать с молоком матери, как гром среди ясного неба, зуд в языке, закрывать глаза, драть шкуру, дурной глаз, длинный язык, держать камень за пазухой, взять под свое крылышко**

2. Мәкальләрнең икенче яртысын тәмамлап куярга:

**Күз – куркак, кул - ... . Корал эшләр, ... ... . Бүгенге эшне ... ... . Калган эшкә ... ... . Үзең төпле белмичә ... ... . Тик ятарга ... ... . Тыйнакның кулы эшләр, ... ... ... . Тырышкан тир кипмәс, ... ... ... . Ялкауга эш кушсаң, ... ... ... ... . Эше барның ашы бар, ... ... ... ... . Тирләп эшләсәң, ... ... . Батыр яуда беленер, ... ... ... .**

## КИЛЕП ЧЫГЫШЫ ЯГЫННАН ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ЛЕКСИКАСЫ

1. ***Татар лексикасының формалашуы.*** Татар теленең сүзлек составы күп гасырлар дәвамында туплана килгән. Аның формалашуында, үсүендә төп ике юлны күрсәтеп булыр иде: 1) татар теленең үз сүзләре җирлегендә, 2) башка телләрдән сүзләр алу юлы белән.

Татар теленең үз сүзләре хәзерге татар теленең төп сүз фондын тәшкил итә. Шуның өстенә, татар теленең сүзлегендә

башка кардәш төрки телләре белән уртак сүзләр дә күп. Мәсәлән, *ат, ут, су, баш, күз, кыз, ир, тау, бер, ике; яхшы, ялкын, якын, юл, җимеш, җил, ел, йөк, йөрәк, аю, балык, яшел, камыр, карын, ярты, тары, сары, арык, ачык, ярык, кавын, камыш, кашык, сабын, тимер һ. б.* сүзләр башкорт, казах, кыргыз, үзбәк, уйгур һ. б. телләрдә бер үк төрле дип әйтерлек яңгырыйлар.

2. ***Татар теленә башка телләрдән кергән сүзләр.***

***Гарәп һәм фарсы телләреннән кергән сүзләр.*** Татар теленең сүзлек составында гарәп һәм фарсы телләреннән кергән сүзләр күп. Аларның күбесе әдәбият һәм культура, фән һәм мәгариф өлкәсенә, җәмгыять, дәүләт төзелеше, администрация һәм идарә эшләренә, гаилә, көнкүреш, хезмәт һәм гореф-гадәт төшенчәләренә, сәүдә-экономика, медицина, хокук, дин өлкәләренә һ. б. карый.

***Гарәп*** теленнән кергән сүзләргә мисаллар: *азат, әләм, ахирәт, битараф, ватан, газап, гыйшык, гөнаһ, данә, мәктәп, китап, дәүләт, дивар, дәвер, дәрья, дәрәҗә, әдәбият, зәгыйфь, зарар, игълан, игътибар, илтифат, илһам, ихлас,ихтимал, кабилә, кагыйдә, каләм, канун, китап, котып, кыйтга, кәеф, ләззәт, матбугат, микъдар, милләт, тарих, мирас, михнәт, миһербан, морат, муафикъ, мәгариф, мәгъ-лүм, мәгънә, мәет, мәел, мәйдан, мәкаль, мәкер, мәрхәмәт, мәсәл, мәхрүм, махсус, мәшгуль, мәҗбүр, мохит, намус, начар, нигъмәт, нисбәт, нокта, нотык, нәзер, нәфес, нәфис, нәшрият, пакь, рәхим, рәхәт, рух, рәис, рәсем, рәсми, рәсүл, сахра, сихер, солых, сурәт, сыйныф, сыйфат, сәбәп, сәер, сәлам, сәламәт, сырхау, сәфәр, сәхнә, сәяхәт, сәүдә, табигать, тамаша, тәвәккәл, тәгаен, тәгам, тәгъбир, тәкъдир, тәмам, тән, тәнкыйть, тәртип, тәхет, тәэсир, тәүбә, тәүфикъ, фараз, фаш, фаҗига, фигыль, фида, фидакарь, фикер, фирка, фәкыйрь, фәлсәфә, фән, хайван, хак, хаким, хасил, хата, хат, хафа, хикәя, хилаф, хисап, холык, хосусият, хур, хуҗа, хәвеф, хәер, хәрби, хәреф, хәрәкәт, хәсрәт, хөрмәт, шарт, шивә, ширбәт, шәфкать, шәһәр, шөбһә, шөгыль, шөкер, ядкәр, ятим, әгъза, әлбәттә, әлифба, әләм, әманәт, әмер, әмма, әсәр, әхлак, әүлия, өмет, җавап, җенес, җинаять,*

*җиһан, җөмлә, һава, һәйкәл, һәйбәт, һәлакәт, һәм, һаман* һ. б.

Фарсы теленнән кергән сүзләргә мисаллар: *абруй, былбыл, бәхет, бәһа, баһадир, гауга, гәрчә, гәрәбә, гөман, гөнаһ, гүр, дивана, дошман, дәрман, дәһшәт, зыян, зәһәр, кәгазь, кәрван, надан, падишаһ, сөрмә, фәрман, шаять, шимбә, җанвар, һич* һ. б.

***Рус теленнән кергән сүзләр.*** Татар халкы борын-борыннан руслар белән икътисади, сәүдә, сәяси һ. б. мөнәсәбәтләрдә булган. Шуңа күрә татар теленә рус теле сүзләре дә күпләп кабул ителгән. Мәсәлән, *бүрәнә, ужым, мич, парта, колхоз, совхоз, самолет, совет, водород һ.* б. сузләр татар теленә рус теленнән кергәннәр.

Сүзләрнең купчелеге татар теленең үз фонетик законнарына буйсындырылганнар: *сука, буразна, салам, өстәл, бидрә, ләгән, чәйне, тәлинкә, эшләпә, келәт, торба, әвен, арыш, канау, кәбестә, мәк, мүк, пумала, сумала, мунчала, тәмәке, борыч, кесәл* һ.б.

Татар теленә рус теле аша башка телләрдән дә күп сүзләр кергән.

***Инглиз теленнән:*** *пиджак, бифштекс, комбайн, кекс, волейбол, рельс, митинг, футбол, байкот, импорт, стандарт, фильм, памфлет, буфер, доллар, клоун, чемпион, рекорд һ.б.*

***Немец теленнән:*** *галстук, бухгалтер, гроссмейстер, слесарь, ракета, гастроль, лозунг, полиция, банкрот, штурм, рейс, парламент, шахта, штаб, цех, ордер, штанга, турнир, фокус, шпион, масштаб һ.б.*

***Француз теленнән:*** *сезон, балет, трюмо, багаж, киоск, инвалид, костюм, соус, ресторан, партия, авангард, бюро, декрет, атака, десант, тир, грим, антракт, экран, марш, деталь, газон, парашют, комиссар, тираж, тариф, ферма, маршрут, лотерея, парад, жанр, сюжет.*

***Грек һәм латин телләреннән:*** *пленум, биология, декан, драма, теорема, грамота, хор, индустрия, агрегат, транспорт, мотор, аппарат, радио, радиатор, коммунизм, материализм, демонстрация, республика, территория, реакция, колония, эмигрант, делегат, академия, химия, фактор, формула, элемент, аспирант, стипендия, аттестат, конкурс,*

*публицистика, автор, нигилизм, сатира, позиция, агрессия, операция, витамин, инфаркт, актив, логика, диалектика, морфология, оптика, эстетика, психология, физика, философия, гипноз, аксиома, догма, метод, планета, анархизм, гимн, поэзия, поэма, ода, талант, ритм, лирика, музей, диагноз, эпоха, фантазия, программа, система, график* һ. б.

***Итальян теленнән:*** *либретто, аккорд, тенор, карикатура, новелла, соло, капелла, соната, трио, макарон, вермишель, конфета, фонтан, салфетка, контрабанда һ.б.*

## КУЛЛАНЫЛУ ДӘРӘҖӘСЕ ЯГЫННАН ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ СҮЗЛЕК СОСТАВЫ

Телнең сүзлек составы фән һәм техниканың, икътисад мәдәният, әдәбият һәм сәнгатьнең үсүенә бәйләнешле рәвештә баеп, камилләшеп тора. Сүзлек составыннан искер, гән сүзләрнең бер төркеме төшеп кала, кайберләре яңа мәгънә алып китә һәм шулай ук өр-яна сүзләр дә ясала.

Кулланылу дәрәҗәсенә карап, татар телендәге сүзләрне өч группага бүләргә мөмкин:

1) **Актив сүзләр.** Боларга элек тә һәм хәзер дә бер үк дәрәҗәдә еш кулланылучы сүзләр керә: *җир, су, Һава, агач, кеше, эш, йорт, аш, утын, бүрәнә, мич, кием, оек, киртә, бакча, авыл, шәһәр, китап, каләм, дәфтәр, кәгазь, яхшы, начар, эшләү, ясау, төзү, йөрү, тиз, акрын, биек, югары, матур, җылы, кайнар, эссе, салкын, елга, җәй, кыш, яз, көз* һ. б. Мондый сүзләрне тел белемендә актив лексика дип йөртәләр.

2) **Искергән сүзләр.** Җәмгыять үсү белән бергә анын икътисади тормышы, мәдәнияте алга китә, яңа иҗтимагый-сәяси мөнәсәбәтләр туа. Иске тормыш-көнкүрешкә, гореф-гадәтләргә, иске ижтимагый-сәяси мөнәсәбәтләргә һ. б. бәйле сүзләр пассивлаша, актив лексикадан акрынлап төшеп кала. Мәсәлән, *алпавыт, патша, казый, хаҗи, сөңге, ук, җәя, сука* һ. б. сүзләр үткән чорларда актив кулланып та, хәзер кулланылыштан төшеп калган төшенчәләрне белдерәләр, телдә, пассивлашканнар. Алар иске дәверләр тормышын тасвирлау

өчен тарихи китапларда ня файдаланылалар.

3) **Яңа сүзләр.** Промышленность һәм авыл хуҗалыгы, фән Һәм техника, мәдәниятнең үсеше, яңа иҗтимагый мөнәсәбәтләр туу белән яңа предметлар, күренешләрнең атамалары барлыкка килә. Яңа сүзләр үзләренең яңгырашлары белән башта сәер тоелырга мөмкин, ләкин вакытлар үтү белән аларның бик күбесе халыклашып китә һәм актив лексикага күчә, ә бер өлеше пассив лексикада торып кала, кулланылыштан бөтенләй төшеп югала. Мәсәлән, *юлбашчы, сүзлек, тракторчы, комбайнчы, колхоз, совхоз* һ. б. сүзләр инде яңа сүзләр түгел, алар актив лексикага күчкән сүзләр исәпләнәләр. Ә менә *космодром* сүзе яңа, чөнки ул әле сәер яңгырый, телдә үзләшеп кенә килә.

## ИСКЕРГӘН СҮЗЛӘР

Искергән сүзләрне ике категориягә бүлеп йөртәләр:
1) тарихи сүзләр, 2) архаизмнар.

**Тарихи сүзләр.** Кулланылыштан төшеп калган күре-неш, предметларның атамалары тарихи сүзләр дип атала: *алпавыт, бояр, хан, урәтник, ахун, морза, кантон, өяз, ка-бак, җәдит, талак, чикмән, камзол, чабата, чулпы, сука, киле, торпыча, шүре, ярлык* һ. 6.

**Архаизмнар.** Кайбер күренешләр, предметлар элекке атамасы белән түгел, бүгенгесе белән йөртелә: *укытучы (мөгаллим* түгел), *мәктәп (мәдрәсә* түгел), *көнчыгыш (шәрык* түгел), *диалект (шивә* түгел) һ. б.

Димәк, әгәр тарихи сүзләр искергән, юкка чыккан кү-ренешләрнең атамалары булса, архаизмнар — хәзерге көндә дә булган күренешләрнең искергән атамалары.

## КУЛЛАНЫЛУ СФЕРАСЫ ЯГЫННАН ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ЛЕКСИКАСЫ

Кулланылу сферасы ягыннан татар теленең лексик байлыгы 4 төркемгә бүленә:

1. гомумхалык лексикасы;

2. диалект лексикасы (диалектизмнар);
3. профессиональ-терминологик лексика;
4. жаргоннар.

## СҮЗЛЕКЛӘР ТУРЫНДА КЫСКАЧА МӘГЪЛҮМАТ

Сүзлекләр турындагы фән лексикография дип атала.

Сүзлек - ул сүзләр исемлеге. Билгеле, гадәттә сүзлектә сүзләр исемлеге генә бирелми, аларга аңлатмалар бирелә, мәгънәләре төшендерелә, ул сүзләрнең нинди әйберләрне, күренешләрне белдерүләре аңлатыла, сүзләрнең әйтелеше, язылышы, килеп чыгышы һ. б. хакында белешмәләр китерелә.

**Сүзлекләрнең төп төрләре.** Төп ике тип сүзлекләрне күрсәтергә мөмкин: 1) энциклопедик сүзлекләр, 2) лингвистик сүзлекләр. Энциклопедик сүзлекләр әһәмиятле предметлар, күренешләр, атаклы кешеләр, вакыйгалар һ. б. турында сөйлиләр. Лингвистик сүзлекләр сүзләргә багышлана.

**Аңлатмалы сүзлекләр.** Лингвистик сүзлекләр арасында аңлатмалы сүзлекләр үзәк урынны алып тора. Беренчедән, алар сүзнең иң әһәмиятле якларын (мәгънәсен) ачып күрсәтәләр, икенчедән, күп төрле мәгънә төсмерләрен һ. б. бирәләр. Бу сүзлекләрдә әйтелеш, язылыш, этимология һ. б. мәсьәләләр дә берникадәр яктыртыла.

**Башка төрле сүзлекләр.** Аңлатмалы сүзлекләрдән тыш, тәрҗемәле сүзлекләр (татарча-русча, русча-татарча, гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге, русча-немецча һ. б. сүзлекләр), диалектологик сүзлекләр, этимологик сүзлекләр, синонимнар сүзлеге, омонимнар сүзлеге, фразеологик сүзлекләр, орфографик сүзлекләр, орфоэпик сүзлекләр, терминологик сүзлекләр һ. б. була.

### Белемнәрне тикшерү өчен контроль биремнәр.

### Вариант - 1

***1. Исем сүз төркеменнән булган 5 омоним уйлап языгыз.***

***2. Төрле сүз төркемнәреннән 10 омоним уйлап табып, алар белән җөмләләр төзегез.***

***3. Татарча-русча сүзлекләрдән омонимнарга 5 мисал табып языгыз. Аларны кертеп, җөмләләр уйлагыз.***

***4. Бирелгән сүзләрне нәрсәгә нигезләнеп омонимнарның бер төре (омофоннар) дип әйтергә була?***

Туп ал — тубал, зур аю — зураю, карт аю — картаю, кар ак — карак, су-кырларны — сукырларны, зур ат — зурат, сары ут — сарут, пар ат—парад, кызса —кысса, алты ай — Алтай, тары ала микән—тарала микән.

***5. Парлап бирелгән сүзләрнең һәр икесе дә бер үк мәгънә белдерәләрме? Татар әдәби телендә кайсысы кулланылырга тиеш дип уйлыйсыз?***

Әңгәмә — беседа, энергия—көч, хозяйка — хуҗа хатын, конфликт — бәрелеш, набат — чаң, работник — эшче, километр — чакрым, спорт площадкасы — спорт мәйданчыгы, художник — рәссам, пленный — әсир, семья—гаилә, выговор—шелтә, часовой — сакчы, сотрудник — хезмәткәр, пограничник — чик сакчысы, ящик—әрҗә, конюшня — ат абзары, одеял — юрган, адвокат —яклаучы, следователь — тикшерүче, блокнот — куен дәфтәре, эскәтер — ашъяулык, общежитие — тулай торак, учетта тору — исәптә тору, группа — төркем, результат—нәтиҗә, кыска срок — кыска вакыт, почтальон — хат ташучы, детдом — балалар йорты, кружок — түгәрәк, звание — дәрәҗә.

***6. Гарәп һәм фарсы телләреннән кергән бу сүзләрнең татарча синонимнарын табыгыз.***

Абруй, хәстә, нигъмәт, гаскәр, мәшһүр, шәфкать, җәмгыять, фидакяр, гайре, игълан, нәкыш, мәгълүм, фәрман, әҗәт, азат, тәмам, чор, гариза, низаг, шифа, нам, ядкяр, бәгъзе, ләгънәт, хәвеф-хәтәр, вәхши, мәзәк, зәгыйфь, риза, морад, пакь, сихри, файда, хәзинә, мәхәббәт, фәкыйрь, әсир, вәгазь, хасият, һөнәр.

***7. Рус теле аша кергән бу сүзләр нинди өлкәләргә карый?***

Парламент, демократия, митинг, съезд, самодержавие, фракция, республика, депутат, администрация.

Армия, фронт, дивизия, полк, батальон, гарнизон, окоп, солдат, офицер, генерал, погон, шинель, разведка, винтовка, пулемет.

Театр, партер, пьеса, драматургия, трагедия, труппа, вальс, опера, романс, хор, соната, бас, рояль, скрипка, нота, флейта, гармун, клуб.

Университет, гимназия, рецепт, гипноз, консилиум, градус, микроб, цензура, институт, кафедра, энциклопедия, анатомия, молекула, атом.

Коридор, кабинет, буфет, кухня, квартира, стена, фонарь, кресло, лампа, фитиль, эскәтер, графин, салфетка, тәлинкә, стакан, ваза, самовар.

***8. Түбәндә китерелгән тотрыклы сүзтезмәләрнең бер сүз белән белдерелгән синонимнарын языгыз.***

Җиде бабасын таныту, кул арасына керә башлау, җилгә туздыру, кул уйнату, теле телгә йокмау, борын салыну, үлеп тору, балавыз сыгу, табан ялтырату, сөмсере коелу, теге дөньяга китү, чәч үрә тору, әлифне таяк дип тә белмәү, баш ию, колакка салу, күз бәйләнү, куенда таш йөртү.

***9. Бирелгән фразеологик берәмлек һәм мәкальләрне кертеп, кечкенә генә бер хикәя төзеп языгыз. (30-40 җөмлә)***

Арслан йөрәкле булу; батыр ярасыз булмас; сукса тимер өзәрлек; тез чүгеп яшәүдән басып үлү яхшырак; ир егет үзе өчен үләр; калтырап төшү; куян җанлы; курку басу; батыр яуда беленер.

***10. Түбәндәге ясалма фигыльләрдә нинди уртак ясагыч кушымча бар? Схемада күрсәтегез.***

а) Йогышсызландыру, җиһазландыру, күркәмләндерү, канәгатьләндерү, зәгыйфьләндерү, дымландыру, күбекләндерү, тапландыру, рухландыру, татуландыру, ямьләндерү, үтмәсләндерү, тәмләндерү, көпшәкләндерү.

***Фигыль ясаучы кушымчалары аерып чыгарыгыз.***

б) Сәхнәләштерү, кинолаштыру, аралаштыру, мәңгеләштерү, хәрбиләштерү, гадиләштерү, татарчалаштыру, гомумиләштерү, калькалаштыру, берләштерү, үзәкләштерү, механикалаштыру, планлаштыру, рәсмиләштерү, саңгыраулаштыру.

***11. Мисалларны укып чыгыгыз, сүзләрнең төзелешен һәм ясалышын тикшерегез, кайсы сүз төркеменә каравын***

***билгеләгез. Мисалларны түбәндәге тартиптә күчереп алыгыз. Җөмләләр төзегез.***

а) тамыр сүзләр;

б) ясалма сүзләр;

в) кушма сүзләр;

г) парлы сүзләр;

д) тезмә сүзләр;

е) конверсия юлы белан ясалган сүзләр;

ж) кыскартылма сүзләр.

Миләш чыпчыгы, укытучы, ватык, кар, буйлы, көчкә, күз буяу, мүк җиләге, урман тавыгы, башта, урманлык, нефтьче, СМУ, вуз, берникадәр, аэрочана, автохуҗалык, озын, баш әйләнү, ата-ана, аю колагыз, күз күреме, урыс кукысы, кәлтә елан, тиктормас, төклетура, сиртмәкойрык, этле-мәчеле, үзкыйммәт, тилзәнеш, үзгәртеп кору, үзфинанслау, ара-тирә, су-саклагыч, партком, райком, сертотмас, КДУ, кардәшлек, санау-лы, яттан, пыр тузу, кызылканат, озынборын, ярдәм итү, ләчтит сату, очыш, сөмсере коелу, такъдим итү, күз ташлау, рәхим-шәфкать, сау-сәламәт, сафсата сату.

## Вариант – 2

***1. Фигыль сүз төркеменнән булган 5 омоним уйлап языгыз.***

***2. Төрле сүз төркемнәреннән 10 омоним уйлап табып, алар белән җөмләләр төзегез.***

***3. Татарча-русча сүзлекләрдән омонимнарга 5 мисал табып языгыз. Аларны кертеп, җөмләләр уйлагыз.***

***4. Түбәндәге сүзләр арасында охшашлык бармы?***

Искермәсен—ис кермәсен, барында — барын да, Гөлүсә — гөл үсә, бик мул ла — Бикмулла, яңа гына — яңагына, кар атып — каратып, ал да диеп—алда диеп, тар калу — таркалу.

***5. Түбәндәге парлап китерелгән сүзләрнең мәгънәләре бер төслеме? Алар бар очракта да бер-берсен алыштырып килә алалармы? Кулланылышы пассивлашканнары бармы?***

Абруй — авторитет, Алман — Германия, сандугач — былбыл, бәгъзе — кайбере, дискуссия — бәхәс, ваба — үләт, кадерле — газиз, бүтән —гайре, бик — гаять, зиндан — төрмә,

экономик — икътисади, имтихан — экзамен, кешелек — инсаният, логика — мантыйк, атаклы — мәшһүр, укытучы — мөгаллим, председатель — рәис, сыйныф — класс, рәссам — художник, кайгы — хәсрәт, ләгыйнь—юньсез, ләб—ирен, мөхбир — хәбәрче, рисалә — мәкалә.

***6. Төркемләп бирелгән бу гарәп-фарсы сүзләре кайсы өлкәләргә карый? Татар телендә аларның алынма икәнлеге сизеләме?***

1. Гыйлем, дәрес, дәфтәр, мисал, мәгариф, мәдрәсә, мәктәп, мәсьәлә, сабак, нокта, хәреф, җөмлә, мөгаллим, тәрбия, имтихан, каләм, тәнәфес, әсбап.

2. Матбугат, сәнгать, нәшрият, рәссам, рәсем, иҗат, тарих, китапханә, рухи, мөхәррир, сәхнә.

3. Әдәбият, шигырь, мәкаль, газәл, нәсер, тасвир, мәдхия, хикәя, тәрҗемә, мәснәви, рәдиф, әсәр, тәнкыйть, сурәт, мәсәл, мәкалә, кыйсса, дастан.

4. Сишәмбе, чәршәмбе, заман, вакыт, чор, рамазан, җомга, гасыр.

5. Ватан, дәүләт, тәхет, тарих, таҗ, хөкүмәт, гаскәр, патша, җәмгыять, вәзир, сыйныф, әмир, вәзир, милләт.

6. Аваз, кагыйдә, сыйфат, сан, исем, җөмлә, заман, фигыль, хәбәр, нисби, хәл, хата, әлиф, җавап, зат.

7. Дин, ахирәт, вәгазь, казый, иман, мәчет, дога, садака, хәер, фәрештә, хода, хәрам, мөфти, пәйгамбәр, әүлия.

***7.Исемнәрнең фигыль омонимнарын табып, җөмләләр төзеп языгыз.***

Ат, үт, яр, кер, тап, куй, ач, чалу, агу, койма, кап, атау, ис.

***8. Түбәндәге сүзләрнең русча кулланылышта булган синонимнарын табып язарга.***

Әңгәмә, бәрелеш, чакрым, рәссам, гаилә, әрҗә, юрган, куен дәфтәре, ашгьяулык, төркем, хат ташучы, абруй, бәхәс, икътисади, имтихан, рәис, сыйныф, пешекче, йола, янгын, шифаханә, ашамлык.

***9. Бирелгән сүзләрне стилистик битараф һәм билгеле бер стильдә генә кулланыла торган лексикага аерып языгыз.***

Урман, су, чәлү, чәпү, җә*я,* идән. койма, болыт, күз, яшен,

пычак, ычкыну, сары, поезд, томыру, ачык авыз, исем, вакыт, моңаю, олагу, эш, бүре, малай, тар, кычкыру, акыру, сез, мин, гүзәлем, эифа, тыкшыну, түзү, тәүге, Ватан, углым, китап, каз, үләнле, гөлкәем, сыптыру, карурман, аһәң, горур, сәгадәт, уҗым бозавы, тырмашу, тугры, сылу, үткәрүчәнлек, нурланыш.

***10. Бирелгән фразеологик берәмлек һәм мәкальләрне кертеп, кечкенә генә бер хикәя төзеп языгыз. (30-40 җөмлә)***

Арслан йөрәкле булу; батыр ярасыз булмас; сукса тимер өзәрлек; тез чүгеп яшәүдән басып үлү яхшырак; ир егет үзе өчен үләр; калтырап төшү; куян җанлы; курку басу; батыр яуда беленер.

***11. Түбәндәге исемнәрдә ясагыч кушымчаларны күрсәтегез, кайсылары — искергән, кайсылары актив икәнен әйтегез.***

Бишлек, казанлы, мәскәүле, икеле, акча, бармакча, сызыкча, яшелчә, сыекча, төшенчә, төркемчә, уенчык, янгык, җыерчык, валчык, бөркәнчек, урманчылык, укытучылык, дәүләтчелек, азчылык, түбәнчелек, эшсезлек, әдәплелек, кызыллар, яшелләр, аклар, җилгәргеч, тишкеч, чәчкеч, очкыч, белгеч, нурланыш, төзелеш, очыш, үзгәреш, чигеш, аерма, аңлатма, учма, эремә, салма, оешма, төймә, шарлавык, боерык. ярык, сызык, тишек, катык, торак. елак, аксак, кунак, телем, чыгым, әйтем, бирем, белем, үлем, явым, агым, чәнечке, ышкы, чалгы, себерке, оеткы, утенеч, таяныч, сөенеч, ышаныч, үсенте, сырганак, тузганак, тигәнәк, урындык, култык, җыентык, кушылдык, икмәк, чүлмәк, тармак, күлмәк, тормыш, җимеш, яра, күбә, кыя, җәя, инә, сука, чәйханә, ашханә, басмаханә, елнамә, юраунамә, сөюнамә, Татарстан, Төрекмәнстан, Казахстан.

## Сүз ясалышы

Татар телендә сүз бер яки берничә кисәктән – морфемадан гыйбарәт. <u>Морфема</u> – сүзнең мәгънәгә ия булган иң кечкенә кисәге.

Мәсәлән, уку-чы-лар-га. Беренче сүзнең тамыры -уку- ул

үзгәрми торган кисәк, сүзнең төп лексик мәгънәсен белдерә. Соңгылары сүздә я аның мәгънәсен үзгәртәләр (уку-чы), я аны төрләндерәләр, я башка сүзгә бәйләп киләләр (-лар, -га). Димәк, сүзнең реаль мәгънәгә ия булган иң кечкенә кисәге тамыр дип атала.

Бер тамырдан гына ясалган сүзләр тамыр нигезле, тамыр һәм ясагыч кушымчалардан гына торган сүзләр ясалма нигезле, ике яки өч тамырдан торган сүзләр кушма нигезле булалар. Мәсәлән, авылда – тамыр нигез, авылдаш – ясалма нигезле, Актырнак – кушма нигез. Сүзнең төрләндергеч кушымчаларын аерып алганнан соң калган өлеше нигез дип атала.

Кушымчаларны вазифалары буенча сүз ясагыч һәм форма (төр) ясагычка бүлеп карыйлар.

Сүз ясагыч кушымчалар, тамырга я нигезгә ялганып, яңа мәгънәле лексик берәмлек барлыкка китерәләр. Мәсәлән: чор – чор+даш, баш – баш+лык, эш – эш+че, баш – баш+ла.

Форма ясагыч кушымчалар сүзгә яңа грамматик мәгънә төсмере өстиләр, сүзнең формасын үзгәртәләр. Болар килеш, сан, тартым, зат-сан, заман, юнәлеш, дәрәҗә, юклык һәм затланышсыз фигыль кушымчалары.

Күнегү 1. *Түбәндәге сүзләргә -ла, -лә кушымчалары ялгап, фигыльләр ясагыз.*

1) эш –
ау –
камыт –
чүкеч –
кыргыч –
йозак –
дага –
җиһаз –
җилем –

2) уйнак –
кадерсез –
чатан –
аксак –
иркен –
ышык –

Күнегү 2. *Түбәндәге сүзләрнең тамырларын һәм уртак сүз ясаучы кушымчаны табыгыз. Таблица ясап, урнаштырыгыз.*

Сабаклану, төлкеләнү, кибәкләнү, канатлану, куллану, тезләнү, дәртләнү, дулкынлану, саңгыраулану, факыйрьләнү,

кырыслану, үртәләнү, икеләнү, икенчеләнү, сырпалану, яргалану, тернәкләнү, чәбәләнү, кабалану, этәчләнү, ерткычлану, өметләнү, хыяллану.

Күнегү 3. *Түбәндәге исемнәрдә ясагыч кушымчаларны күрсәтегез, кайсылары – искергән, кайсылары актив икәнен әйтегез.*

Бишлек, казанлы, мәскәүле, икеле, акча, бармакча, сызыкча, яшелчә, сыекча, төшенчә, төркемчә, уенчык, янчык, җыерчык, валчык, бөркәнчек, урманчылык, укытучылык, дәүләтчелек, азчылык, түбәнчелек, эшсезлек, әдәплелек, кызыллар, яшелләр, аклар, җилгәргеч, тишкеч, чәчкеч, очкыч, белгеч, нурланыш, төзелеш, очыш, үзгәреш, чигеш, аерма, аңлатма, учма, эремә, салма, оешма, төймә, шарлавык, боерык, ярык, сызык, тишек, катык, торак, елак, аксак, кунак, телем, чыгым, әйтем, бирем, белем, үлем, явым, агым, чәнечке, ышкы, чалгы, себерке, оеткы, үтенеч, таяныч, сөенеч, ышаныч, үсенте, сырганак, тузганак, тигәнәк, урындык, култык, җыентык, кушылдык, икмәк, чүлмәк, тармак, күлмәк, тормыш, җимеш, яра, күбә, кыя, җәя, инә, сука, чәйханә, ашханә, басмаханә, елнамә, юраунамә, сөюнамә, Татарстан, Төркмәнстан, Казахстан.

Күнегү 4. *Парлы сүзләрнең төзелешен тикшереп чыгыгыз. Алар нинди сүз төркемнәренә карыйлар, компонентлар үзара нинди мәгънәләрдә торалар? Исем, сыйфат, фигыль сүз төркемнәренә караганнарын баганалап яза барыгыз.*

Ил-су, дус-иш, ил-күз, савыт-саба, явым-төшем, урын-җир, җиләк-җимеш, туган-тумача, ярлы-ябагай, иге-чиге, яше-карты, аталы-кызлы, ирле-хатынлы, иртәле-кичле, язу-сызу, ару-талу, киенү-ясану, этү-төртү, яну-көю, ашау-эчү, алдым-бирдем, ордым-бәрдем, юк-бар, кирәк-ярак, якын-тирә, кызгылт-көрән, зәңгәрсу-соры, саргылт-күк, тимгел-тимгел,

кат-кат, отчет-сайлау, рус-татар, идея-политик, ала-кола, кызыл-яшел, ач-ялангач, вак-төяк, кәкре-бөкре, чиле-пешле, караңгылы-яктылы, очсыз-кырыйсыз, эзсез-хәбәрсез, кайгы-хәсрәт, килде-китте, узган-барган, күргән-белгән, туган-үскән,

кагу-сугу, әйләнү-тулгану, бер-ике, җиде-сигез, ул-бу, бер-бер, рәт-рәт, бөртек-бөртек, аты-чабы, ачлы-туклы, уйнап-көлеп, тирләп-пешеп, түкми-чәчми, ипилек-тозлык, икәүдән-икәү, аннан-моннан, берәм-сәрәм, аз-маз.

Күнегү 5. *Кушма сүзләрнең ясалу үзенчәлеген һәм кайсы сүз төркеменә каравын әйтегез. Җанлы предметны белдергән сүзләрне – бер баганага, җансыз предметны белдергәннәрен икенче баганага языгыз.*

Ташкүмер, ташбака, тимераяк, ташпулат, үрдәкборын, тукранбаш, күкебаш, укъяфрак, мөгезборын, тузбаш, билбау, ашъяулык, китапханә, башкала, каенага, суүсем, чынаяк, радиодулкын.

Күнегү 6. *Түбәндәге сүзләрне мәгънәле кисәкләргә – морфемаларга бүлегез һәм һәр морфеманың мәгънәсен аңлатып бирегез.*

Җитешсезлекләрне, киптергечтән, имәнлектәге, төрләнеш, калыплашкан, эшчәнлегенең, игътибарсызлыгы, аңлашкан, сөземтәнең, шаркылдашулары, кабарынкы, корылмалы.

Күнегү 7. *Түбәндәге исемнәрнең ясалышында нинди уртаклык бар? Шул сүзләрне кертеп җөмләләр языгыз.*

Энә карагы, кәҗә сакалы, кош теле, эт балыгы, күз кабагы, имән чикләвеге, нарат гөмбәсе, энҗе чәчәге, күз карасы, урман тавыгы, су үгезе, тау кәҗәсе, әдәбият белеме, чүп үләне, мәче борчагы, чәч толымы, кунак өе, бал корты, печән өсте, идән асты, акыл иясе, балта остасы, бака яфрагы.

Күнегү 8. *Мисалларны укып чыгыгыз, сүзләрнең төзелешен һәм ясалышын тикшерегез, кайсы сүз төркеменә каравын билгеләгез. Мисалларны түбәндәге тәртиптә күчереп алыгыз:*

а) тамыр сүзләр;
б) ясалма сүзләр;
в) кушма сүзләр;

г) парлы сүзләр;

д) тезмә сүзләр;

е) конверсия юлы белән ясалган сүзләр;

ж) кыскыртылма сүзләр.

Миләш чыпчыгы, укытучы, ватык, кар, буйлы, көчкә, күз буяу, мүк җиләге, урман тавыгы, башта, урманлык, нефтьче, СМУ, вуз, берникадәр, аэрочана, автохуҗалык, озын, баш әйләнү, ата-ана, аю колагы, күз күреме, урыс кукысы, кәлтә елан, тиктормас, төклетура, сиртмәкойрык, этле-мәчеле, үзкыйммәт, тизләнеш, үзгәртеп кору, үзфинанслау, ара-тирә, сусаклагыч, партком, райком, сертотмас, КДУ, кардәшлек, санаулы, яттан, пыр тузу, кызылканат, озынборын, ярдәм итү, ләчтит сату, очыш, сөмсере коелу, тәкъдим итү, күз ташлау, рәхим-шәфкать, сау-сәламәт, сафсата сату.

Күнегү 9. *Түбәндәге сүзләрне морфемаларга бүлергә:*

| | | |
|---|---|---|
| төтенли | серләшкән | казылма |
| чуалчыклар | япмалары | талгынлык |
| сүрәнәйде | күпчелегенә | эшчәнлегенең |
| ятсыну | яраклаша | каңгылдашулары |
| кисенте | хәрәмләшү | кимчелек |
| үкенечле | тәҗрибәсезлеге | чыжылдаган |
| чыганаклардан | кыймылдатмый | төшенкелекне |

Күнегү 10.

1) *Бер үк төрле кушымча ярдәмендә ясалган сүзләрне төркемләп языгыз. Бу сүзләрне нинди мәгънә уртаклыгы берләштерә?*

аваздаш, тимерче, чапкыч, тамырдаш, җыйгыч, ташчы, юлдаш, авылдаш, ургыч, колхозчы, эшче, көрәк, сәяхәтче, илче, терәк, капкачы, сызык, бүлек.

2) *Түбәндәге тамыр сүзләргә кушымчалар ялгап, яңа мәгънәле сүзләр ясагыз.*

- бел-, тот-, оч-, эл-, җәй-;
- матур, якты, яшь, кызык;
- юл, баш, канат, уй.

Күнегү 11. *Баганалап язылган ясалма исемнәрнең сүз ясалыш мәгънәсен билгеләгез.*

| | | |
|---|---|---|
| алтынчы | чабатачы | уракчы |
| күмерче | дугачы | китмәнче |
| цементчы | сабынчы | тракторчы |
| нефтьче | сөтче | тупчы |
| тимерче | кашыкчы | барабанчы |
| бакчачы | елкычы | ленинчы |
| игенче | малчы | республикачы |
| мамыкчы | куянчы | мәгърифәтче |
| хәлвәче | балыкчы | монархияче |

Күнегү 12. *Китерелгән ясалма сүзләрнең төзелешен һәм мәгънәләрен аңлатыгыз. Аннары уртак кушымчалы, уртак сүз ясалыш мәгънәсенә ия булган сүзләрне сүз ясалыш типларына аерыгыз.*

Качкын, үткен, упкын, ташкын, чапкын, янгын, кискен, тоткын, баскын;

чапкы, ышкы, тойгы, чалгы, көлке, йокы, пычкы, себерке, чәнечке;

тезем, явым, кабым, кисем, бәйләм, бүлем, сөйләм, агым, катлам, йотым, чеметем, телем, саплам, йомарлам, үлем, сызым, учлам.

Күнегү 13.

*Көн, кыз-, көч, көл-, эч-* сүзләреннән ясалган сүзләрне ояларга җыеп языгыз, оя эченә кергән сүзләрнең чылбырларын да тезегез.

Эш тәртибен *бәй* тамырыннан ясалган сүзләр үрнәгендә аңлатабыз:

1. Бәй тамырыннан ясалган барлык сүзләрне сүзлектән күчереп языгыз: бәй, бәйле, бәйлек, бәйлә һ.б.
2. Кушымчаларны ялгану тәртибе буенча үрнәктәгечә таркатып языгыз:

   <u>бәй</u> - ле - лек

- сез - лек
- лек

бәй – лә - веч - ле
- геч
- ү - ле
- м – лә

бәй – лә - н - чек - лек

бәй – лә - ш - ле - лек
- сез - лек

3. Сүз ясалыш ояларын язып алыгыз. Ничә оя ясап була?

| | | | |
|---|---|---|---|
| | -ле | | -веч |
| Бәй | -сез | | -геч |
| | -лек | Бәйлә | -ү |
| | -лє | | -м |
| Бәйлән | -еш | Бәйләнеш | -ле |
| | -чек | | -сез |

4. Сүз ясалыш чылбырларын тезегез:

Бәй – бәйле – бәйлелек
Бәй – бәйсез – бәйсезлек
Бәй – бәйлә – бәйләвеч – бәйләвечле
Бәй – бәйлә – бәйләү – бәйләүле
Бәй – бәйлә – бәйләм – бәйләмле
Бәй – бәйлә – бәйлән – бәйләнчек – бәйләнчеклек
Бәй – бәйлә – бәйлән – бәйләнеш – бәйләнешсез – бәйләнешсезлек
Бәй – бәйлә – бәйлән – бәйләнеш – бәйләнешле – бәйләнешлелек

Күнегү 14. *Ясалма сүзләргә сүз ясалыш анализы ясагыз. Эш тәртибен үзегез билгеләгез.*

Чүкеч, себерке, урак, ышкы, бүлмә, таяныч, сырма, мәгърифәтче, көрәк, көенеч, чапкы, туңдырма, чәнечке, игенче, тукма, тарак, төнәтмә, балыкчы, курайчы, кабартма, үкенеч, ачкыч, ярма, япма, стахановчы, гармунчы, гайбәтче.

Күнегү 15. *Мисалларны укыгыз. Сүзләрнең төзелешен һәм ясалышын тикшерегез, сүз төркемен билгеләгез. Аннары мисалларны түбәндәге тәртиптә күчереп языгыз: 1. ясалма булмаган сүзләр; 2. ясалма сүзләр; 3. кушма һәм тезмә сүзләр; 4. конверсия ысулы белән ясалган сүзләр; 5. тотрыклы һәм ирекле сүзтезмәләр.*

«Киләчәккә хатлар» поэмасы, киләчәкбез, берьяклы, берьюллы, ачкүзлелек, песи табаны, әкәм-төкәм, эңгер-меңгер, эшлекле, игелекле, белдекле, яшүсмер, гадәттә, гөлҗимеш, кулбаш, утлау, утлык, бердәнбер, күз буяу, туган-тумача, дөнья-күләм, буар елан, бәйнә-бәйнә, баш әйләнү, эт җимеше, бүре җиләге, урып җыю, бизгәк тоту, укытучы, күргән-белгән, ярым-рәсми, янарчәчәк, җәбер-золым, килгән-киткән, килделе-киттеле, сайлаулар, телдән төшмәү, телдән (сөйләү), соңыннан, бервакыт, ду килү, бораулаучы, тиздән, кычкырып (сөйләшү), бергәләшеп, яшьтән, ат кузгалагы, тын алу, имтихан алу, җан бирү, йөрәккә төшү, үзәккә үтү, һичшиксез, яттан (сөйләү), калдык-постык, калды, калҗа, калач, көлке, төлке, өске, йозак, кадак, сөяк, ватык, китек, өзек, буйдак, буйлы, буйчан, буйсын, башлык, башсыз, башкисәр, баштанаяк, яңабаштан, яңадан, башак, баштан, башта, баш имәс, баш тарту, башка килү, башка чыгу, баш әйләнү, баш мәкалә, башваткыч, башлыча, очкыч, очып килү, очып чыгу, очкын, очар кош, түземсезлек, тәрбияче, бәйрәмче, башкача, озынча, тукранбаш, көчкә, дымсыз, янартау, сусыл, аксыл, кул кую, тиктормас, искитмәүчәнлек.

Күнегү 16. -лы, -сыз *кушымчаларын ике функциядә (ясагыч кушымча һәм сүз бәйләүче чара булып) килүенә, китерелгән мисалларда күзәтеп, ике баганага аерып языгыз:*

Җәяүле кеше, шешәле су, башлы шикәр, аз сүзле кеше, башлы кеше, аклы ситса, көчсез бала, мәрхәмәтсез кеше, өстәлле бүлмә, китаплы киштәләр, сулы чәйнек, күгәрченле рәсем, картиналы бүлмә, өстәлсез бүлмә, иптәшсез уйныйм, мәктәпсез авыл, икмәксез ашау, сусыз шешә.

*Үзегез дә ике очракка мисал уйлап языгыз.*

## Сүз төркемнәрен һәм аларның грамматик категорияләрен тикшерү тәртибе

### Исемгә морфологик аналаз

1. Ялгызлык яки уртаклык исеме.
2. Ясалыш ысулы һәм ясалыш структурасы.
3. Кайсы килештә булуы, шул килеш ярдәмендә кайсы сүзгә бәйләнүе һәм белдергән мөнәсәбәте.
4. Берлектә яки күплектә булуы.
5. Тартым белән төрләнгән булса, аның заты-саны һәм кайсы сүзгә караганлыгы.

### Сыйфатка морфологик анализ

1. Сыйфатның төркемчәсе.
2. Ясалыш ясулы һәм ясалыш структурасы.
3. Кайсы сүзне ачыклый?
4. Асыл сыйфат булса, дәрәҗәсе.
5. Исемләшкән булса, кайсы сүзне алыштырып килә һәм исемнең кайсы категорияләре белән төрләнә?

Тышта игенченең җилегенә үтә, ашлыклы черетә торган бәйләнчек вак яңгыр ява иде. (Г. Бәширов)

<u>игенченең</u> – уртаклык исеме, ясалма (иген-че), иялек килешендә (игенченең җилегенә – иялек мөнәсәбәте), берлектә;

<u>җилегенә</u> – уртаклык исеме, тамыр сүз, юнәлеш килешендә (җилегенә үтә – кыек объект), 3-нче зат берлектәге тартымлы (<u>игенченең</u> сүзенә карый);

<u>яңгыр</u> – уртаклык исеме, тамыр исем, баш килештә: яңгыр ява – ия белән хәбәр мөнәсәбәте;

<u>бәйләнчек</u> – асыл сыйфат, ясалма (бәйлән-чек), төп дәрәҗә, яңгыр сүзен ачыклый;

<u>вак</u> – асыл сыйфат, тамыр, төп дәрәҗә, яңгыр сүзен ачыклый.

### Рәвешкә морфологик анализ

1. Рәвешнең төркемчәсе.
2. Ясалыш ысулы һәм структурасы.
3. Кайсы сүзне ачыклап килүе.

4. Исемләшкән булса, төрләнеше.

Гайнан күптән үк торган булса да, бернигә кулы бармыйча, үзен кая куярга белмичә, тәрәзә каршына килеп басты. (Г. Бәширов)

Күптән – хәл (вакыт) рәвеше, конверсия юлы белән ясалган (күп сүзенең чыгыш килеш формасы аерымланып, катып калган), торган булса да фигылен ачыклый.

## Алмашлыкка морфологик анализ

1. Алмашлыкның төркемчәсе.
2. Кайсы сүз төркемен алмаштыру ягыннан төркемчәсе.
3. Ясалыш ысулы һәм структурасы.
4. Төрләнсә, нинди категорияләр белән төрләнүе.

бернигә – юклык алмашлыгы, исем алмашлыгы, кушма (бер + ни) сан һәм алмашлыктан тора, юнәлеш килешендә (бернигә кулы бармый);

үзен – билгеләү алмашлыгы, исем алмашлыгы, тамыр, тартымлы төшем килешендә (үзен кая куярга);

кая – сорау алмашлыгы, рәвеш алмашлыгы.

## Санга морфологик анализ

1. Санның төркемчәсе.
2. Ясалыш ысулы һәм структурасы.
3. Бәйле яки бәйсез кулланылышы.
4. Төрләнгән булса, нинди категорияләр алган.

Шырпы тартмасы белән тоз алды, өч-дүрт бәрәңге кыздырды. (Г. Бәширов)

өч-дүрт – чама саны, парлы сан, бәйле кулланылган: исемне ачыклап килә, төрләнмәгән.

## Фигыль һәм аның төркемчәләренә анализ

Барлык фигыльләрнең, нинди төркемчә булуына карамастан, ясалыш ысулы һәм структурасы, юнәлеш категориясенә мөнәсәбәте һәм төркемчәсе әйтелә.

## Хикәя фигыльне тикшерү

1. Заманы, заты-саны, барлык-юклык формасы.
2. заманның төп парадигматик мәгънәсе. Тикшерелә торган җөмләдә нинди мәгънәдә килүе.

Югарыда китерелгән мисаллардагы хикәя фигыльләрне тикшерик:

1. ява иде – тамыр фигыль, төп юнәлештә, тәмамланган үткән заман хикәя фигыль, 3 нче зат берлектә, үткән, дәвамлы процессны белдерә – заманның төп мәгънәсендә;
2. килеп басты – тезмә фигыль (ике фигыльдән тора), төп юнәлештә, категорик үткән заман хикәя фигыль, 3 нче зат берлектә, тәмамланган һәм бер тапкыр булган эшне белдерә – төп мәгънәдә, тезмә фигыльнең нигезе - килеп бас-, заман күрсәткече -ты;
3. кыстырды – кыс-тыр-ды: тамыр фигыль, йөкләтү юнәлеше, категорик үткән заман хикәя фигыль, 3 зат берлектә, төп мәгънәсендә.

## Боерык фигыльне тикшерү

1. Заты – саны.
2. Боеруның мәгънә төсмере.
3. Күчерелмә мәгънәдә булса, аңлатыла.
4. Боеру мәгънәсендә башка форма булса, аңа тулы аңлатма бирелә.

## Шарт һәм кире шарт фигыльне тикшерү

1. Шарт һәм кире шарт фигыльнең ясалышы.
2. Шарт фигыльнең тикшерелә торган җөмләдә заманга мөнәсәбәте.
3. Шарт фигыльгә бәйләнгән төп фигыльнең формасы.
4. Реаль фаразый һәм реаль булмаган шарт.
5. Күчерелмә мәгънәдә булса, аерым күрсәтелә.
6. Шартны белдерү өчен башка формалар килсә, аларга анализ ясала.

Теләкне белдерә торган формалар һәм конструкцияләр

1. Теләк наклонениясе яки башка формалар.
2. Бу формалар төзелеше.
3. Заты-саны һәм аның белдерү юлы.
4. Синонимнары.

Мөмкинлек, кирәклек, тиешлек, ният кебек модаль формалар

1. Модаль мәгънә билгеләнә.
2. Белдерү чарасы һәм аның нинди формалар белән ясалганлыгы, зат-санга, заманга мөнәсәбәте.

Үрнәк:

- Әни кайтсын әле, күр дә тор, барыбер әйтәм!
- Сөйлән әле, яме! – диде Һәрун, кычкырып.

(Н. Фәттах)

кайтсын (әле) – 3 нче зат берлек сандагы боерык фигыль; әле кисәкчәсе белән килеп, янауны, куркытуны белдерә.

күр дә тор – 2 нче зат берлек сандагы боерык фигыльдән ясалган тотрыклы сүзтезмә.

сөйлән (әле) – 2 нче зат берлек сандагы боерык фигыль, бу контекстта шулай ук янауны һәм эштән тыюны белдерә (барлык формада килсә дә, юклыкта – «сөйләнмә» мәгънәсендә килгән).

Җир салкынча иде әле. Ә көн җылы, аяз буласы… Аңа ашыгырга кирәкми, ул беркая да соңламый инде. Аңа хәзер шушылай утырасы гына… Сөнгатулланың мыштым гына елыйсы килде. (Ә.Гаффар)

Көн… аяз буласы – тиешлек формасы, (аның үз иясе бар, димәк 3 нче затны белдерә) – асы кушымчалы сыйфат фигыльгә нигезләнгән. Синонимы: булырга тиеш.

/аңа/ утырасы/гына/ - шул ук форма бу очракта кирәклекне белдерә, иясе юк, башкаручы ирә юнәлеш килешендәге зат алмашлыгы белән белдерелгән. Синонимы: утырырга гына кирәк.

елыйсы килде – ел/а/+ыйсы кил-де: ела – фигыльнең нигезе ясалма (аг-ла >егла >ела); -ыйсы/ -исе, -асы, -єсе/+кил теләк формасы, -ле – категорик үткән заман күрсәткече, башкаручысы иялек килешендәге исем белән белдерелгән.

Затланышсыз фигыль формаларын тикшерү: сыйфат фигыль

1. Заманы, заманның төре һәм ясалышы, барлык-юклык.
2. Җөмләдәге функциясе: предметны ачыклыймы, предметны алыштырып исемләшеп килгәнме, яки исем фигыль функциясендә кулланылганмы?
3. Төрләнсә, категорияләрен күрсәтергә.

Беренче җөмләдән мисал (16б.):

черетә торган (яңгыр) – хәзерге заман сыйфат фигыльнең икенче формасы, барлыкта, ясалышы – ә торган, җөмләдә аергыч булып килгән, яңгыр сүзен ачыклый.

Әйе, кайчан да булса бер аның белән барысын да ачыктан-ачык сөйләшәчәгенә, барысын да аңлашачагына ул әз генә дә шикләнмәде. (Н. Фәттах)

сөйләшәчәгенә, аңлашачагына – киләчәк заман сыйфат фигыль формасы; ясалышы – сөйләш-әчәк, аңлаш-ачак; бу җөмләдә – исем фигыль функциясендә: сөйләшүенә, аңлашуына мәгънәсенә якын, соңгысыннан киләчәк заман төсмере белән аерыла; 3 нче зат берлектәге тартым белән төрләнгән (үзенең сөйләшәчәгенә, …), юнәлеш килешендә.

Хәл фигыль

1. Хәл фигыль формасы, барлык-юклык төре.
2. Төп эшкә мөнәсәбәте.

Түбән төшеп, автобус күпергә керде.

Урман, корыган имәннәре белән сырхаулап һәм яшь наратлары белән яшәреп, артта калды. (Ә.Гаффар)

төшеп – төш-еп: тамыр фигыль, хәл фигыль формасында, барлыкта, төп эштән (күпергә керде) алда булган эшне белдерә;

сырхаулап, яшәреп – ясалма фигыльләр: сырхау-ла-п, яш-әр-еп, хәл фигыль формасында, барлыкта, төп эш белән (артта калды) бергә башкарылган эш-хәлне белдерә.

Исем фигыль һәм инфинитив

1. Төркемчәсе, формасы, барлык-юклык төре.

2. Исем фигыль булса төрләнеше: килеше (мәҗбүри), тартымы (заты-саны белән), берлектә яки күплектә булуы.

Тора-бара тормыш җиңеләйгәч, артка борылып карарга да, киләчәккә омтылырга да курка башлады. Ул калган бәхетенең шушы хәрәкәт дәртендә, кызының аны кайгыртуында икәнен уйлады. (Ә. Гаффәр)

карарга, омтылырга – тамыр фигыль, инфинитив, -рга, -ырга кушымчасы белән ясалган, барлыкта;

кайгыртуында – ясалма фигыль: кайгы-р-т, йөкләтү юнәлешендә, исем фигыль, -у кушымчасы белән ясалган, 3 нче зат берлек сандагы тартымлы (кызының кайгыртуы), урын-вакыт килешендә.

## Ике фигыльдән торган тезмә (аналитик) фигыльләрне тикшерү

1. Тезмә нигез табыла.
2. Һәр компонентның семантик өлеше билгеләнә.
3. Нигездән соң килгән кушымчаларга карап, тезмә фигыльнең җөмләдәге формасы билгеләнә.

Өй бусагасын атлап керүгә, кискен авыртудан аның югалта язып, ишек төбенә урталай бөгелеп төште.

атлап керүгә – аналитик фигыль, нигезе – атлап кер-, формасы ү+гә – исем фигыль, юнәлеш килешендә;

тезмә нигез – атлап кер-: атлап (хәл фиг.) – төп мәгънә;

кер – ярдәмче фигыль, эшнең юнәлешен һәм ахырынача үтәлүен белдерә;

югалта язып – аналитик фигыль, нигезе – югалта яз-, формасы –ып, хәл фигыль;

тезмә нигез: югалта яз: - югалта (хәл фиг.) – төп мәгънә;

яз – ярдәмче фигыль, эшнең үтәлү алдында туктап калуын белдерә;

бөгелеп төште – аналитик фигыль, нигезе – бөгелеп төш-, формасы –те – категорик үткән заман хикәя фигыль, 3нче зат берлектә;

тезмә нигез: бөгелеп төш-: бөгелеп (хәл фиг.) – төп

мәгънәне белдерә;

төш - ярдәмче фигыль; эшнең кинәт башланып, тиз тәмамлауын белдерә (өлешчә төп мәгънәсе дә саклана).

<u>Ярдәмлек сүз төркемнәрен тикшерү. Бәйлек.</u>

1. Сүз төркеме билгеләнә.
2. Бәйлекнең нинди килешне таләп итүе һәм кайсы сүзләрне бәйләве, мәгънәсе әйтелә.
3. Бәйлек сүзләрнең бәйлектән аермасы күрсәтелә: төп сүз белән изафә бәйләнешендә булуы, урын-ара (юнәлеш, чыгыш, урын-вакыт) килешләрнең берсендә булуы әйтелә.
4. Конверсия юлы белән барлыкка килгән бәйлек һәм бәйлек сүзләргә аңлатма бирелә.

<u>Теркәгеч</u>

1. Сүз төркеме, теркәгечнең төркемчәсе, нәрсәләрне бәйләве аңлатыла.
2. Теркәгеч сүзләрнең хезмәте һәм нәрсәдән ясалганлыгы әйтелә.
3. Теркәгеч ролендә килгән башка чаралар күрсәтелә.

<u>Кисәкчә</u>

1. Кисәкчә белдергән мәгънә әйтелә.
2. Кулланылыш урыны буенча төркемчәсе күрсәтелә.
3. Язылыш кагыйдәсе әйтелә.
4. Башка сүз төркемнәре кисәкчә мәгънәсендә килсә, аңлатыла.

<u>Ымлыклар</u>

1. Ымлыкның кайсы төркемчәдән булуы, мәгънәсе күрсәтелә.
2. Башка сүз төркемнәре ымлык функциясендә килгән очраклар билгеләнә.

<u>Аваз ияртеме</u>

1. Аваз яки образ ияртеме булуы әйтелә.

2. Нәрсәгә охшатылганы аңлатыла.
3. Ничек кулланылганы (мөстәкыйль яки фигыль составында килүе) билгеләнә.

Үрнәк:

Аларның хәзер кыш буена җитәрлек утыннары бар. Бала-чагалары белән җылы өйдә кыш чыга алалар. Әмма ике көн рәттән сигезәр-унар сәгать суыкта торып, … Нурия авырый башлады. (Г.А.)

буена – бәйлек сүз, кыш сүзе белән II төр изафә бәйләнешендә, юнәлеш килешендә (кыш һәм җитәрлек сүзләрен бәйли);

белән – бәйлек, баш килешне таләп итә, бала-чагалары белән (кыш чыга алалар) сүзләрен бәйли, бергәлекне белдерә;

әмма – төзүче теркәгеч: каршы куючы. Контекстта ике җөмләне, кара-каршы куеп, бәйли.

## Исем

Күнегү 17. *Исемнең нинди санда килүен билгеләргә. Сан категориясе тагын нинди мәгънәләр белдерә ала?*

Арбалар яныннан үзенә бер тантана белән, иген кырларының батырлары: Тәзкирәләр, Гөлнурлар, бүтәннәр атлыйлар. (Г.Б.) Күпчелеге – хатын-кыз. Аларның да яртысыннан артыгы балалы хатын. (Г.К.) Һәммәбездә шул Такташлар каны, вакыт-вакыт уты ала көйрәп. (Р.З.) Өйләнеп та карамаслар, тотса мәскәүләр якаң. (Г.Т.) Хатлар яздым ярыма, Мәскәү калаларына. (М.Җ.) Яза белсәм, үзәкләрен өздерерлек итеп, барысын да аңлатып шигырь язып бирер идем дә шуннан соң, бәлки, акылына килер иде. (В.Н.)

Күнегү 18. *Исем сүз төркеменә тулы морфологик анализ ясарга:*

Аның йөзендә алсу шәүлә балкый, ә күзләре шатлык белән елмаялар иде. (К.Н.) Озын йомшак сөлгесе белән сөртенә-сөртенә вагондагы бүлмәсенә керде. (Г.К.) Мин өмәчеләрдән

соңарак калып, үз атымны менеп кенә бардым. (Г.И.) Тимсих күлендәге суда кешенең бата алмавы турында сөйлимме сиңа? (М.Ю.) Дөньяда иң зур бәхет ул, илләр гизеп кайткач, сине сагынып көтә-көтә күз нурларын коеп бетерә язган газиз әниең белән бер табында сөтле чәй эчеп утыру. (Ф.Ш.) Шәм-Суарның горурлыгы – җиде капка, Ап-ак ташлы юллар килә төрле яктан, Килгәннәргә илең күрсәт, җирен күрсәт, Мактанырлык чамаң булса, әйдә, мактан! (М.Ш.) Дулкыннан катер дер селкенә, ә алар, тимер палубага ябышып үскән кебек иэнәрен-иңгә куеп басканнар да приказ көтәләр. (Ф.Ш.)

Күнегү 19. *Г. Бәширов әсәрләреннән китерелгән өзекләрдән тамыр сүзләрне һәм ясалма исемнәрне аерып, баганалап языгыз.*

1. Халыкның тормыш тәҗрибәсен, фәлсәфәсен, гореф-гадәтен, шигъриятен, фәнен, тарихын, ниһаять, һәрбер халыкның халык булучылыгын мең еллар буенча саклап килүче бетмәс-төкәнмәс бер байлыгы бар. Ул – аның теле. Телнең шундый соклангыч сыйфатлары, шундый гаҗәеп хасиятләре һәм куәте бар ки, уйлыйсың да хәйран каласың. 2. Әлиф-бине дә, әбҗәдне дә ятлыйсың, кыен булса ясинның да «башына» җитеп, һәфтияккә «төшәсең». Әмма шунысы бик гаҗәеп, укыганнарыңның мәгънәсен дә, аларның нигә кирәклеген дә белмисең. Чөнки гарәп сүзләрен тәрҗемәләп аңлатмыйлар, аларны бары тик дин сабагы итеп кенә түкми-чәчми ятлаталар гына иде … 3. …Шушы аңлаешсыз һәм эчпошыргыч дәрәҗәдә күңелсез сафсатаны ятлый торгач, ялыкканбыз, күрәсең, хәлфә абзый чыгып китү белән, без күмәкләшеп яңа шигырьләр укырга, үз телебездә җырларга тотына идек. Безнең шикелле үк шәкертләрнең күңелсез тормышы турында язылган бер шигырь безгә бик тә ошады. Без аны көйләп укый торган булдык. Мин аны соңрак кына белдем: ул шагыйребез Габдулла Тукайныкы икән.

Күнегү 20. *Исемгә морфологик анализ ясагыз.*
Ялгызлык яки уртаклык исеме булуын күрсәтегез.

Үрнәк: *Балачакка (кайтарды) – уртаклык исем, кушма исем, юнәлеш килешендә, кайтарды сүзенә иярә, берлек санда,*

*эшнең урынын белдерә.*

Сагыну мине балачакка кайтарды. Авылда атнага бер базар. Зур базар. Кышкы салкында чана табаны тавышы әллә каян колакка ярып керә. Төнлә йокы аралаш килеп керә. Чана ыңгыраша, зарлана. Беләм, бүрәнә салып марилар төннән үк базарга киләләр. Әти китап ярата. Булса, үзебезнең базарда сатып ала. Бездә булмаса, Әтнә базарыннан сатып алып кайта. Чана башында атка салам, печән. Салам эчендә капчык, ипи кисәге һәм китап … Атна арасында бураннарга да карамастан, кечкенә чана тартып, китап сатучы килеп чыга. Өстендә кайры тун, аякта чуар киез итек. Керә, китапларын сәкегә җәеп сала. Үз китапларына үзе сокланып бер читтән карап тора. Безнең күзләр шул китапларда. Әни чәй куя. Бәйрәм бит, бәйрәм. Бездән күрше йортка, безнең авылдан күрше авылга китә. Яңадан бураннар эченә кереп югала. Буранда, салкында ак тунлы кеше берүзе генә йөри кебек … (С.Х.)

Күнегү 21. *Оялап бирелгән синоним исемнәрдән җөмләләр төзегез. Аларның мәгънә төсмерләрен аңлатып бирегез.*

Гариза, үтенеч; дәлил, нигез, аргумент; исем, ат, нам; очкыч, аэроплан, самолет; аш, азык, аш-су, ашамлык, нигъмәт, ризык, тәгам, азык-фәлән; батыр, каһарман, баһадир, пәһлеван, герой; бала, сабый, нарасый, яшүсмер, олан, углан.

## Сыйфат

Күнегү 22. *Сыйфатларга тулы морфологик анализ ясарга.*

Аксыл матур йөзе миләш капкан кешенеке кебек чытылып куя. (Ш.Р.) Санаулы көн бик тиз килеп җитте. (Ф.Х.) Ул киеренке төннән соң, Нәҗипнең бер күз кабагы тарта башлады. (З.Ф.) Анда каракучкыл тузан болыты күтәрелә, куәтле гүелдәүләр, ачы ыжгырулар колакны тондыра. (Э.К.) Ул тагын да матуррак булып күренә миңа. (Н.Д.) Баһау абый аңардан кайтышрак буйлы, югарак гәүдәле, кара чәчле, җиде төн уртасындагы караңгыда да янып торгандай кап-кара күзле, ап-ак тешләре балкып китә торган көләч йөзле егет. (Ш.М.) Тиктормас

холыклы Нәбиев сәяси сизгерлек күрсәтүне кирәксенде. (Ш.Р.) Бүре күзге томанлы төннәрдә, язгы иртәләрдә килүчән. (М.М.)

Күнегү 23. *Сыйфатларның дәрәҗәләрен билгеләргә. Ясалма сыйфатларның сүз ясалышын тикшерергә.*

Кунакны каршы алырга юантык кына тәбәнәк буйлы, озынча нечкә борынлы, кечкенә, ләкин ерткыч кошныкы кебек үткен күзле Миһри җиңги үзе чыкты. (Ә.Ф.) Зур-зур тимгелле аксыл болыт астыннан кояш ялтырап чыкты. (З.Ф.) Асфальт сукмак аларны скульптуралар куелган ямь-яшел аланлыкка китереп чыгарды. (С.Ш.) Өстендә сыек зәңгәр җирлеккә күкле-яшелле эре-эре чәчәкләр төшерелгән крепдешиннан тегелгән купшы күлмәк, аягында күксел ефәк оек. (М.Ә.)

Күнегү 24. Ә. *Гаффарның «Яшиселәр бар әле» повестеннан алынган өзекләрдә сыйфатларны күчереп языгыз һәм анализ ясагыз.*

Бу урында елга зур борылыш ясый. Яр текә, биек. Аста – яшел сулы тоба, ул тирән, төбендә – соры төстәге балчык. Киң селтәнеп чапкан чалгы эзедәй яткан борылышта Сөнгатулла үзен ничектер кечерәеп калгандай тойды.

Аръякта авыл көтүе йөрер өчен сукаланмый калдырылган озынча болын: кара-каршы торган үрләр арасындагы тар иңкүлеккә кереп киткәнче, ул болында иртәләрен авыл көтүе таралып, чемченеп ала, көне буенча колхозның ат көтүе утлап йөри Болынның теге ягындагы үр кашы буенча таш юл сузылган.

Күзне чагылдыргыч кояшлы көн иде. … Болынны кыйгачлый кистергән юлда печән чапкычлар таккан көпчәкле трактор күренде. … Сөнгатулла «Коммунар»ын кабызганчы төгәл һәм гайрәтле хәрәкәтләрен күңелендә барлап чыкты.

… Ул сугышка дошманны ни өчен, кем өчен үч алырга икәнен яхшы белеп китте. Күрше Мәһируза апаның ире һәм аларның дүрт кызы, укытучы Асия апа, Гарифә әби … өчен, үсеп килүче, искергән бишмәтле, чабаталы, ямау салган итекле, ябык, моңсу ятимнәр өчен … үч алырга әзер иде ул. (Ә. Гаффәр)

Күнегү 25. *Сыйфатларны табып, күчереп языгыз. Аларның ясалу үзенчәлекләренә игътибар итегез.*

Бу китабымны язганда, миңа ярты гасыр артка чигенеп, сукалы-тырмалы, оек-чабаталы яшь чагыбызга кире катырга, шул заман теленә яңадан колак салырга ихтыяҗ чыкты. Хәзерге авыл халкының күпчелеге әдәби телдә сөйләшә диярлек. Моннан илле-алтмыш ел элек исә авыл кешесенең, бигрәк тә халыкның керәшен дип йөртелгән өлешенең, Бикәби һәм Кирушларның теле ифрат та узенчәлекле иде. Күрәсең, керәшеннәр теленә Көнчыгыштан килгән гарәп һәм фарсы сүзләре күп керә алмаганлыктан, аларда борынгы телнең искерә төшкән элементлары күбрәк саклангандыр. Бу ярты гасыр эчендә әдәби телебез дә, халык сөйләме дә шундый үсте, шулкадәр баеды һәм үзгәрде ки, хәзер инде Бикәбиләр теле анахронизм булып яңгыраса, һич тә гаҗәп түгел.

## Рәвеш

Күнегү 26. *Рәвеш сүз төркеменә тулы морфологик анализ ясарга.*

Арлы-бирле йөренгәли торгач, Зиннәт яңадан тәрәзә янына барып басты. (Г.Б.) Ә кичә-бүген, күр әле, күңеле белән ихтиярсыздан диярлек туарылды да куйды (Э.К.) Сизелер-сизелмәс кенә ияк тә кага. (Б.К.) Бу кичтә тагын бер күзгә-күз сөйләшү булды. (Г.Ә.) Иртәгесен тагы чана тартып су буена төште Рәхимҗан. (Р.М.) Туп арбаларын тартып баручыларга икеләтә авыр иде. (Ш.Р.) Берөзлексез үкереп торган зур-зур ике бульдозер белән тарткалаша иде карт тирәк чишмәсе. (Р.М.) Алар теләгәнчә, алар хыялланганча килеп чыкмады (С.Ш.) Алар үзләре юньләп күренмиләр дә. (Г.Б.) Шул көннән алып, Сафуан абый минем белән һәрчак олыларча сөйләшә башлады. (М.Г.) Әнә бит элеккечә үк чырылдамаса да, хәвефләнеп безнең тирәдә бөтерелә, очына. (Р. Низ.) Күпләр күрми дә калгандыр әле аны. (М.В.)

Күнегү 27. *Рәвешләрне табыгыз. Аларга тулы морфологик*

*анализ ясагыз.*

1. Көн искиткеч матур! (М.Ә.) 2. Заһит, дулкынланып, сак кына хәрәкәтләр белән конвертны ачты. (М.Ә.) 3. Наратлар тыбенә басып, шыксыз тулай торакка керәсе килмичә, без озак тордык. (М.М.) 4. Биредә тарихи дөреслекне раслаучы миллионнарча томнарда гаять мөһим, бәһа биреп бетергесез кадерле документлар саклана. (Ш.М.) 5. Язучылык эшеннән тыш ул (М. Җәлил. – Ф.С.) гомер буе кайда да булса хезмәт иткән, еш кына берьюлы ике-өч урында эшләгән. (Р.М.) 6. Ул кинәт китель җиңен терсәгенә чаклы сыдырып куйды. (С. Шак.) 7. Ә Санькаыны, хәзер иң алдан атлаган үсмер дустыбызны, болардан тыш тагын бер бәйрәм көтє. (З.Н.) 8. Ярым уяу, ярым йокылы Газинурның күз алдыннан әле күптән түгел генә булып үткән күренешләр уза. (Г.Ә.) 9. Эшелоннар икесе дә, бик озын булып, гел кызыл вагоннардан торалар. (Ә.Е.) 10. Һәм вагон стенасына ышкылып кына яуган вак яңгыр аша әкрен, ачык ишетелгән җыр, күктән иңгән ак канатлы фәрештәдәй, егетне, ут эчендә яткан җиреннән сак кына күтәреп, каядыр еракка, татлы хыял дөньясына алып китте. Аның хәтта тәне, һавада йөзгәндәй, җиңеләеп калды, акылы ничектер бердән яктырып китте, сизгерлеге искиткеч үткенләште. Җырны инде ул хәзер моң итеп кенә ишетмичә, гаҗәеп ачык сурәтләр тезмәсе итеп тә күрә иде. (Ә.Е.)

Күнегү 28. *Сүзтезмәләрдәге рәвешләрне ясалышлары буенча төп, ясалма, парлы, кушма, тезмә һәм морфологик-синтаксис юл белән ясалган рәвешләргә аерыгыз. Рәвеш ясагыч кушымчаларны күрсәтегез.*

Тәмам бетү, кышын тору, күзгә күз очрашу, башта сөйләү, берсүзсез ризалашу, батырларча һәлак булу, бик матур, урталай бүлү, натуралата түләү, шактый арту, күп белү, берьюлы әйтү, бергә бару, яңадан күрешү, көнозын эшләү, үрле-кырлы сикерү, русча белү, җәен ял итү, кышын очрашу, ашык-пошык эшләү, аватүнә атлау, бушлай бирү, җәяү бару, кызу әйтү, уттай кызару, шактый зур, бертуктаусыз сөйләү, еш кайту, сирәк күрешү, һаман сагыну, байтакка кадәр.очрашу, берүзе эшләү, үтәдән үтә

күрү, аз-маз белү, читтән күренү, кулдан-кулга йөртү, берьюлы әйтеп бирү, авыз эченнән көйләү.

Күнегү 29. *К. Нәҗминең «Алка эчендә» повестеннан алынган өзекне күчереп языгыз. Алмашлыкларның функцияләрен язмача аңлатып бирегез.*

Кытайлар ясаган кәгазь фонарьларны күргәнегез бармы?

Булса, минем уйларым да бүген шундый чуар.

Иртәнге чыкларны яфрак өсләренә салып сәлендергән каенлыкта булганыгыз бармы?

Булса, минем уйларым да бүген шундый моңсу.

Атлар дулыйлар. Олтаны төшкән ботинкалар лаштыр-лоштыр ботакларга эләгәләр. Ләкин аңар караган кеше юк. Отряд һаман алга ыргыла.

Күнегү 30. *Алмашлыкларга тулы морфологик анализ ясарга.*

Бу дөньяда үз өең, үз әниең, үз авылың булудан да кадерле нәрсә бар? Һәм нindидер каһәрле көч сине шушы рәхәтлектән читкә, ятлар арасына тынгысызлыкка куа. Нигә качам мин рәхәтлектән? Урман ягыннан ыңгырашып елаган тавыш тагын ишетелеп китте.

Безнең тынгысыз, бәхиллек тапмый интегеп йөрүебезнең сере бәлки шушы шомлы тавыштадыр? (М.Ю.)

Күрәм, күрәм: җиңә алмый сине
Һичкем, һични, һичбер һәлакәт! (Х.Т.)

Табигатьтәге һәр аваз, һәрбер хәрәкәт мине ымсындыра, магнит сыман үзенә тарта. (Р.Н.) Шуны аңлагач та, җанны миңа билгеле булмаган нindидер бер көч актарып салды, пыран-заран китерде. (Г.К.) Без авыл кешесе. Шушы җирдән чыккан, шушында туган. Табигать безгә, балалары итеп, шундый ундырышлы җир, туфрак биргән. Чишмәләр … Ниндиен телисез – шунысын эчегез. (Р.М.) Сез нәрсә, апа? Кем алай уйлаган? Кайдан чыгып әйтәсез моны? (В.Н.) Бөтен Идел өстенә мул итеп көмеш тәңкәләр сибелгән. (Г.Б.)

Күнегү 31. *Алмашлыкларны түбәндәге тәртип буенча*

*тикшерегез.*

1. Алмашлыкның лексик төркемчәсен әйтегез.
2. Кайсы сүз төркемен алыштыру ягыннан төркемчәсен күрсәтегез.
3. Ясалыш ысулын һәм төзелешен әйтегез.
4. Төрләнгән булса нинди кушымчалар алуын күрсәтегез.
5. Җөмләдәге синтаксик функциясен күрсәтегез.

Җир йөзендәге бөтен малайларның да исемнәре була. Җирән чәчлеме ул, кара чәчлеме, чебен тимәс чер итәрме, каты йодрыклы сугыш чукмарымы – барыбер. Сиңа исемең туганчы ук, әллә кайчан  табылган, табылган гына да түгел – тагылып ук куелган була. Мине дә шулай иткәннәр. Тотканнар да Инсаф дип йөртә башлаганнар. Миңа барыбер. Хет әллә кем дип атаган булсыннар иде. Исемнәр күп бит. Дөнья тулы малайлар, дөнья тулы исем. Шулай булса да, берсе дә ялгышмый, буталышып бетми, Хәбир дисәң, Хәбире «ә» ди, Җәмиле тик тора. Җәмил дисәң, анысы «җә» ди, Хәбире тик тора. Бу әти-әниләр шулкадәр исемне кайдан гына уйлап бетерәләрдер, аптырарсың. Башка малайлар беләләр микән, юк микән, мин үземә нишләп Инсаф диюләрен әллә кайчаннан бирле беләм. Бер елны, мин салкын тиюдән авырып ятканда, авылларыннан әби килгән иде. Ул шунда миңа көчли-көчли, әрли-әрли кипкән җиләк кайнатып эчерде. Инсафның ни икәнен дә ул әйтте. Әбисенең сүзен тыңлап, әче җиләк суын күбрәк эчкән, әмма, җүләрләнеп, тәрәзә бозын яламый торган әдәпле малайларны Инсаф дип йөртәләр икән. *(Г. Мөхәммәтшин. Без әле җирдә яшибез.)*

## Сан

Күнегү 32. *Сан сүз төркеменә тулы морфологик анализ ясарга.*

Инде миңа да киләчәгем турында уйланырга вакыт иде. Унбишем тулды. (Ә.Е.) Бәрәңге төбе саен өч йөз алтмыш градуслы әйләнеш ясап кара әле син. (Г. Каш.) Егерме дүртенче февральдә андагы стачкалар саны ике йөз кешегә җиткән. (Ш.Р.) Сездән бер-бер эш сорарга дип төшкән идем. (Р.М.) Мин колхозның беренче механизаторы. Утыз ел эшләгән. («К.У.») –

Андрей Петрович сезгә туган тиешмени? Беренче ишетәм. (К.Н.) Кырык бала кырык яктан дөнья яңгыратып көлеп җибәрде. (К.Тим.) Өйдән алып киткән чәй, өйдән алып киткән ипи кыергычы икәнен дә беләм, югыйсә, ә барыбер тәме икенче. (М.Г.) Монда инде алты-җиде сәгать кенә соңласаң да күпмегә оттырасың. («К.У.») Кадерлемнең хәлләреннән берәр хәбәр бирсәнә! (Х.Т.)

Күнегү 33. *Сан сүз төркеменә тулы морфологик анализ ясагыз. Анализ ясау тәртибе:*

1. Санның төркемчәсен күрсәтегез.
2. Ясалыш ысулын һәм төзелешен күрсәтегез.
3. Бәйле яки бәйсез кулланылышын аерыгыз.
4. Төрләнгән булса, нинди формалар алуын әйтегез.
5. Җөмләдәге синтаксик функциясен әйтегез.

1. … Улым сорау бирде бер көн: үләннәр турында.
Санап чыктык җиде-сигез үлән исемен.
(Безнең якта алар 300ләп бугай.) (*Р.Ф.*)
2. Бу атнада җөмһүриятебездә фән өлкәсендә ике зур тарихи вакыйга булды. Аның берсе 20 гыйнварда Татарстан Фәннәр академиясенә хакыйкый әгъзалар сайлау белән аңлатылса (бу хакта без укучыларыбызга хәбәр иткән идек инде), икенчесе – кичә әгъза-корреспондентлар сайлау төгәлләнү иде. Шулай итеп, бүген Фәннәр академиясе әгъзаларын тулысынча күзаллау мөмкинлеге туды.

Хакыйкый әгъзалыкка һәм әгъза-корреспондентлыкка икесенә бергә барлыгы 151 гариза кабул ителгән. Шуларның 69ы хакыйкый әгъзалыкка, ә 82се әгъза-корреспондентлыкка дәгъвачылар. Беренче очракта 30 әгъза кирәк булса, икенче очракта 41 әгъзага конкурс игълан ителгән иде. Димәк, 41 әгъза-корреспондент урынына дәгъва белдереп, 82 кеше гариза биргән булып чыга. Шуны да әйтергә кирәк, әлеге 82 кандидат арасында хакыйкый әгъзалыкка үтә алмаган иптәшләр дә конкурста катнашты. 36 кандидат беренче тапкырдан ук, җитәрлек тавыш алып, әгъза-корреспондент итеп сайландылар

(газетадан).

Фигыль

Күнегү 34. *Хикәя фигыльләрне анализларга.*

Җилсез һавада күбәләкләр төсле өн-тавышсыз чуар яфраклар чайкала. (Ә.Г.) Җеп нечкә җиреннән өзелә, дигәннәр шул. (Б.К.) – Хәзер ике-өч минут, чәй өлгертәм. (Б.К.) Ахырдан, берничә еллар узгач, мин «уф алла» арбасы белән бу урманнардан утын ташыдым. Абагалар беткән, мәче башлы ябалаклар да күренми иде. (М.М.) Беләсеңме, ни сөйли торган иде картлар без яшь чакта? (Р.М.) Ахияр инде пенсиягә кадәрге гомерен саный иде, әмма эшсез ятуны күз алдына китерә алмый газапланды. (М.М.) Һич бетәрме тарихи бу бергәлек? – Без туган бер җепкә бергә теркәлеп. (Т.Г.) Төпле акыл дигән хәзинәне һәркемгә дә кучушлап өләшмәгәннәр. (Б.К.) Бу хатыннар җилкәләренә капчыклар күтәргәннәр. (Ф.Х.) Күрәсең, Айбулатов абыйга сәеррәк күзләр белән карап куйганмын. (Г.К.) Ул һичкайчан ашыгып нәтиҗә ясамас, вакыты килеп җиткәнче сабырсызланмас. (Г.А.) Ничек уйлыйсың, Гөлзифә, сынатмабыз бит, ә! (Р.Т.) Тукта, самовар куйыйм, хатларны да бергәләшеп укырбыз, - диде. (К.Т.) – Мондый буранлы төндә кайсы йөрер икән? – диде ул, сукранып. (А.Ш.)

Күнегү 35. *Боерык фигыльләргә морфологик анализ ясарга.*

Кайсы якка гына колак салма, «гөрс» тә «гөрс» җир селкетеп, химаясыз шәһәрләрне җимерде (фашистлар). (Ә.Е.) Аннары тагын ул көй бер милләт моңы эчендә бикләнеп калмасын. Аны үзбәк тә, рус та, татар да – һәммәсе дә аңласын, яратып тыңласын. (Г.Б.) Килегез, сезнең яралылар бездә ничек дәваланалар икән, үз күзләрегез белән күреп китегез. (Ш.Р.) Матур сүзләр сөйләмә, Сафуан. Без аңа күнекмәгән. (М.Г.) Белешеп карагыз әле! – диде. – Берәр укучы контейнер тирәсендә йөрүчене күрмәгәнме? (К.Т.) Менә бар сүзем шул. Зинһар, үпкәли күрмәгез. (С.С.) Хет барагыңның яртысы янып бетсен – уянмыйлар. (Ә.Г.) Тәрәзәмне ачып куйдым, Килсәнә,

җил, керсәнә. (Х.Т.) – Якын киләсе булма, минем тавис бу! Габдулла читенсенеп куйды. (Ә.Ф.)

Күнегү 36. *Үрнәктә күрсәтелгәнчә, җәяләрне ачып, фигыльләрне тиешле заман формасына куеп, җөмләләрне төгәлләп языгыз.*

Үрнәк: Шул чак Халисә шарт-шорт мылтык аткан тавышка күтәрелеп кара- (категорик үткән заман, III зат, берлек сан).

Язарга: Шул чак Халисә шарт-шорт мылтык аткан тавышка күтәрелеп карады.

1. Чишмє ап-ак ташлар арасыннан челтер-челтер итеп агып чык- (хәзерге заман, III зат, берлек сан). 2. Кинәт урман караңгыланып кит- (категорик үткєн заман, III зат, берлек сан). 3. Син күр- (хәзерге заман, II зат, берлек сан, сорау кисәкчәсе ялганган)? 4. Әмма Ык тынычланып җит- (күптән үткән заман, юклык формасы, III зат, берлек сан). 5. Аның янына гранаталар асыл- (нәтиҗәле үткән заман, III зат, берлек сан). 6. Ә без аларны чүпли тор- (хәзерге заман, I зат, күплек сан). 7. – Син нишләп йөр- (хәзерге заман, II зат, берлек сан).

## Затланышсыз фигыль формаларын тикшерү

Күнегү 37. *Хәл фигыльләргә тулы морфологик анализ ясарга.*

Лотфулла Дияров үз-үзен аямыйча, үзенә күп нәрсә таләп итмичә, чын күңеленнән хезмәт итүче фидакарь кеше иде. (Г.А.) Бераз тавыш-тыннар басылгач, күренмичәрәк, сакланыбрак торсак, ничегрәк булыр икән дип әйтмәкче идем. (Г.К.) Күземә карый – карый: - Без генералның үзенә барабызмы, балам? – дип сорады. (Ф.Б.) Әби өй тирәсендә кабаланмыйча гына түтәлләр казый. (Н.Д.) Ямаулы күлмәген лыпырдатып, кәҗәсенә бер уч печән салып тора. (М.М.) Эчем поша башлагач, әби киштәсендә актарынырга тотындым. (Н.Д.) Ничә еллар буе идеаллаштырып, табынып, беркем белән аралаштырмыйча төшләремдә яшереп яшәттем дә, үзе белән очрашкач, куркып, күзләремне йомдым. (Ф.Б.) Әби аларны, мин кайтканчы дип, тастымалларга төреп, эссенен дә суытмый саклаган. (Ф.Б.) Миңа аны күрмичә, аның

белән аңлашмыйча, кире шәһәргә китәргә ярамый. (Ф.Б.) Аның таза аты, юыртуыннан туктамыйча, муенын дугаландырып, ачулы пошкырып, кардан бата-чума узып китте. (Ә.Е.) – Сез тыныч булыгыз, сез Өчиледән кайтканчы, ул бездә булыр, - диде. (Ә.Е.)

Күнегү 38. *Хәл фигыльләрне табып, күчереп языгыз.*

1. Урмандагы бөтен агачлар, дәррәү кубып, берсен-берсе бүлә-бүлә шаулашырга, ухылдашырга керештеләр. (Г.С.) 2. Моңа кадәр йокымсырап утырган җилбәзәк усаклар дерт итеп уяндылар да бөтен урманга шаулаша башладылар. (Г.С.) 3. Урман ышыгында булгач җил туздыра алмый. (Г.С.) 4. Ачкычларын хуҗаларча шалтырата-шалтырата, өстәл тартмасын ачты … (Р.Т.) 5. Әнкәйдән берни яшерми-танмый бәйнә-бәйнә сөйләдем дә бирдем. (Р.Т.) 6. Бичара егет нишләгәнен белмичә, иптәшенә кулын сузды. (Ә.Е.) 7. Кыз түзмәде, тәгәрәп китәрдәй булып, чайкала-чайкала көләргә тотынды. (Ә.Е.) 8. Поезд мәһабәт борылып, соңгы вагон күздән югалганчы карап тордылар да, боек кына урыннарыннан кузгалып киттелєр. (Ә.Е.) 9. Икенче көнне үк төнлә белән котырып давыллы яңгыр килде һәм, дөньяны гарык иткәнче, ишеп-ишеп, чиләкләп койды. (Ә.Е.) 10. Менә дугаларына кызыл тасмалар бәйләгән, чуклар таккан атларга төялеп, яшьләр гармун уйный-уйный, җырлый-җырлый узып киттеләр. (Ә.Е.) 11. Идарә членнары шактый вакыт исләренә килә алмыйча, тын калып, бер-берсенә карашып утырдылар. (Ә.Е.) 12. Мин председатель бүлмәсенә уздым, ләкин өстәленә якын бармыйча, стенадагы төрле плакат-язуларны карарга керештем. (Ә.Е.)

Күнегү 39. *Сыйфат фигыльләргә анализ ясарга.*

Карт аның белән эч пошканнан гына яисә вакыт уздыру өчен генә такылдап утырмый иде. (Г.Б.) Аларга юл буена килергә, юлдан берәрсе үткәнне очратып, авылдагы хәлләрне сөйләтергә кирәк иде. (М.Ә.) Нәчтүк әбинең юраганы юш килде. (М.М.) Мин, иптәш начальник, эшләгән чакта чабудан тартып торганны яратмыйм. (Г.Ә.) Халык арасында таралган даны исә

беренче нәүбәттә, бу күлнең шифалы булуына ышану белән бәйләнгән.(Ә.Е.) Җылы җәйләр, шау чәчәкре язлар гына матур, дип уйлаучылар шаккатсыннар әле. (К.Т.) Галим-голәмә, тарих-археология белән кызыксынучы әдәбият әһелләре, дуслары, танышлары. (С.Ш.) Алар беренче көнне үк авыл советы каршындагы ат бәйли торган урында очрашып күрештеләр. (М.М.) Әллә председательның күзенә генә карап тора торган йомышчы бер малай булырсыңмы? (М.М.)

Күнегү 40. *Сыйфат фигыль формаларының җөмләдәге функцияләрен билгеләгез. Исемләшкән сыйфат фигыльләрне табыгыз. Сыйфат фигыльләрнең заманын күрсәтегез.*

1. Күпме хатирәләр! Китап битләре арасында кипкән чәчәктәй сакланган хатирәләр! (Ә.Е.) 2. Кыз чагындагы самими нәфислегенә үзен бик карый белә торган хатыннарга гына хас нәзакәтле гүзәллек өстәлгән. (Ә.Е.) 3. Ә түбәндә пароход авызыннан әйберләрен күтәргән халык һаман әле агылып чыга иде. (Ә.Е.) 4. Күтәренеп чыгучы пассажирлар да бетеп килә иде инде. (Ә.Е.) 5. Ә төшәсе пассажирлар төшеп беттеләр. (Ә.Е.) 6. Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар. (М.) 7. Ерактан, әллә кайдан, ишетелә күк күкрәгән аваз! (Г.Т.) 8. Иртәрәк өлгереп урман туфрагына төшкәннәре генә алдагы елда шытып чыгар. (М.М.) 9. Күрәсең, каргалар миләш ашый торган атналарда йә көчле салкыннар, йә бураннар булган. (М.М.) 10. …яңа килгәннәр аерым төркем булып утыралар… (М.М.)11. Чит мәктәптә имтихан бирүчеләр арасыннан барысы да уңай билге алдылар. (М.М.)

Күнегү 41. *Исем фигыльләргә тулы морфологик анализ ясарга.*

Хезмәтеңне ярату, аны җиренә җиткереп башкара алу куанычына ни җитә? (Б.К.) Моңарчы Нажар Фәнүзәнең болай ук ачыргалануын, үрсәләнүен күргәне юк иде. (Ә.Б.) Артеллиристлар немецның танк таранын Мостафинның бик җимерүе һәм чигендерүе турында күп сөйләделәр. (Х.К.)

Күнегү 42. *Исем фигыльләрне табып, аларның җөмләдәге*

*функцияләрен билгеләгез.*

1. Фәриха. Син базарга чыкканда килсә, мин ни әйтергә дә белмим дип әйтүем. (Г.И.) 2. - …Миңа бик азга гына ук-җәя биреп тормассызмы диебрәк керүем иде. (Ә.) 3. –Безнеке дә шул инде. Тыныч кына эшләп яту. (А.Я.) 4. Ул нәни йодрыкларын менә болай иттерә-иттерә авызына кабып ятулары…(Р.Т.) 5. – Ул бригаданың печән абзарларына кереп кыек асларыннан күгәрчен тотулар дисеңме …, ул язын җир ачылгач – яланаяк калып, тезеп-тезеп ашык берүләр, сыер ябагасыннан әвәләнгән туплар сугып, чыр-чу килеп, йөгертмә туп уйнаулар дисеңме… Кая калды ул дөньяның гел шатлык кына, гел рәхәт кенә көннәре…(М.Р.)

Күнегү 43. *Аналитик нигезле фигыльләргә анализ ясарга:*

Ачык тәрәзә аша очып керә бал корты. (Ә.Ф.) – Әйе, барып чыкса, шундый исәп юк түгел иде, - диде. (Г.Э.) Ул җир астыннан йөгерә-йөгерә дә, базның икенче башына барып чыга. (А.А.) – Сине Галимҗан Ибраһимов эзли. Хәзер үк аның квартирасына барып чык. (С.К.) Ә мин ун адымнар чамасы алдан көрт ярып бардым. (М.М.) Онытылган чәй шикелле, каны суына бара. (С.Б.) Куптара ала тордым, бозылганнарын түбәнгә ыргыта бардым. (Э.Б.) Ирләрнең бик күбесе шул китүдән әйләнеп кайтмады. (М.Х.) Бусагасын кыюсыз гына атлап үтте дә чак кына көлемсери төшеп исәнләште. (Э.К.) Кичкә таба көн сүрелә төште. (Э.К.) – Йә,ниләр язган соң солдат? Кайчанрак кайтып төшәм дигән? (Э.К.) Картның тавышы шундый шомлы иде, гөр килеп сөйләшеп барган врачлар кинәт тынып калдылар. (Г.А.) Бер көнне арадан берсе әйтә куйды: - Егерме беренче елгы хәл була инде быел. (М.М.) Яңа күренеш вак-төяк борчуларны, көндәлек ыгы-загыны каплап китте. (М.Ю.) Югыйсә врачлары да бар, таныш профессорларны да килеп, җәнтекләп тикшереп китәләр, юк, рәтләнми хәле. (Г.А.)

Күнегү 44. *Өзекләрдән аналитик төзелешле фигыльләрне табып, аерым язып алыгыз. Түбәндәге үрнәк буенча тикшерегез.*

Үрнәк: Урман авызына килеп керүгә ат, сулгарак алдырып, юл читендәге каенга арбаның арт күчәрен китереп ордырды да туктап калды. (М.Г.)

Туктап калды – аналитик төзелешле фигыль, категорик үткән заман, III зат, берлек сан.

Туктап – төп лексик мәгънәне белдерә, *-п* формалы хәл фигыль.

Кал – ярдәмче фигыль, эшнең дәвам итүен белдерә.

1. Кинәт, апаларның чуар итәкләрен бик зур кабартып, салкын җил исте: минем башымдагы өр-яңа кепка, очып төшеп, бик күп аяклар астыннан тәгәрәп китте. Эре-эре тамчылы яңгыр ява башлады. Кешеләр барысы да каядыр ашыгырга, йөгерешергә тотындылар. (Р.Т.) 2. Инде менә көз Клараның бабасы каты авырудан соң үлеп тә китте. Сиксән елдан артык дәвам иткән гөмер өзелде. Барысын да – сагыну-юксынуларын да, җыр-әкиятләрен дә бабай бергә кабергә алып китте.

Хәзер инде гаиләдә Каракошны телгә алучы да юк, «Туган туфрак» дигән сүз үзе үк бөтенләй онытылырга тиеш иде. Ләкин ни гаҗәптер, Клара, бабасы үлгәннән соң, аның әйткән сүзләрен исенә төшергәли башлады. Каракош та әледән-әл күңеленә килгәли торды … (Ә.Е.) 3. Ләкин сарыклар да кинәт тукталып калдылар, гел бергәрәк оешканнан-оеша баралар. Халисә, бар көченә кычкыра-кычкыра, чыбыркысы белән бик үтемле сыптыра-сыптыра, көтүне басу ягына таба куа башлады. (Р.Т.) 4. Кечкенә генә өй эче бермәлгә бала-чага һәм хатын-кызлар белән тулып-китте. Күрше-тирәдән керүчеләр дә бар иде, ахрысы. Һәрхәлдә, шактый югалып калган Клара бу ыгы-зыгы эчендә кемнең кем булуын тиз генә аера алмады. Тик ул үзе тирәсендә бертуктаусыз бөтерелеп, шатлык-иркәләү сүзләре чәчкән какча гәүдәле хатынның кем икәнен бусагадан атлау белән үк танып алды: бу – Хәмдия җиңгәчәсе иде. (Ә.Е.)

Күнегү 45. *Фигыльнең модаль формаларын тикшерегез: алар ничек ясалган, нәрсә белән төрләнгән, нинди мәгънә белдерә? Бу формаларның туры яки күчерелмә мәгънәдә килүен аңлатыгыз, синонимнарын әйтегез.*

1. Монда, иптәшләр, сезнең ярдәмегез кирәк, шунсыз безнең комга утыруыбыз бар. 2. Безгә сафсата сатып, кадерле вакытны алып торганчы, башта ук сүзне шуннан башларга иде! – дип кычкырды арттан бер кеше. 3. Менә шулай трактордан төшмичә барасы да, барасы иде … елга өстеннән томан күтәрелсен иде … Ә машинада! Бер утырдыңмы, җилдәй очасың гына! 4. Никадәр баш ватмасын, шулай да моңа җавап таба алмады. 5. Бездә шундый күмич каршына утыр сора, бәлки аның монда каласы киләдер. – Сорыйсы юк, - диде карт ачу белән. (1-6 Н.Ф.)

Күнегү 46. Ә. *Еники әсәрләре буенча китерелгән мисаллардан модаль мәгънә белдерүче фигыль формаларын табып, асларына сызыгыз. Алар нинди мәгънәләр белдерәләр? Аларны язып алып, мәгънәләрен күрсәтегез.*

| | | |
|---|---|---|
| Үрнәк: | **-әсе иде** | -теләк белдерә |
| | **-асы итте** | -ниятләнүне белдерә |
| | **-рга иде** | -теләк белдерә һ.б. |

1. Аннары ярлы шәкерт бик яхшы укыса гына, үзенең матди хәлен беркадәр җиңеләйтә ала. 2. Чигенергә мөмкин иде, бик мөмкин иде. 3. Әйе, бернинди максатсыз, бары тик коры кызыксынудан гына, үзенә насыйп булмаган Ләйләсен бик тә күрәсе килә иде. 4. Юк, күрәсе иде үзен, ничек тә күрәсе иде. 5. Иленә һәм халкына ихлас күңелдән хезмәт итәсе килә иде. 6. Әгәр очратсам, валлаһи дип әйтәм, ул кызыйны җитәкләп ярга кумакчы идем. 7. Колын булып уйнаклап, шул кылганнар арасыннан чабасы да чабасы килә. 8. Кайткалыйлар иде әле аның уллары яки кызлары, инәләрен онытып бетермиләр иде, исән генә була күрсеннәр инде.

## Инфинитив

Күнегү 47. *Түбәндәге фигыльләргә инфинитив кушымчалары ялгагыз.*

Бас, кал, тарт, көл, төзе, укы, сайла, уйла, эшлә, бие, сора,

сөй, сөрт, әйт, сиз, төш, төя.

Күнегү 48. *Мисаллардан инфинитив формасындагы фигыльләрне табыгыз. Алар ничек кулланылганнар: аерыммы, башка сүзләргә бәйлеме? Инфинитивларның синтаксик функцияләрен билгеләгез.*

1. Сәләховның күз алдына кинәт какларга элгән казлар килеп басты. (М.Ю.) 2. Кесәсеннән хат чыгарып укырга кереште. (М.Ю.) 3. Сәйриннең туган авылында хатыннар яз җитү белән ит какларга, киндер агартырга керешәләр. (М.Ю.) 4. Кем белә, бәлки, киләчәктә аңардан рекомендация дә сорарга туры килер. (Ә.Е.) 5. Хәзер яулыкны үзендә калдырырга да ярамый иде. Йә, нишләтергә тиеш ул аны? Иделгә ташларгамы? 6. …бирәү белән дә уйнамаска-көлмәскә тиешмени инде ул? (Ә.Е.) 7. Яңадан авылга кайтып озак торырга туры килмәде, армиягә алындык. (Р.Т.) 8. …чүмәлә тарттырырга атның иң яхшылары җигелә… (Р.Т.) 9. Концертта без физкультпирамида ясарга тиеш идек. (Р.Т.) 10. Узган җәйдә мин дә түзмәдем, Ташлыярга барып кайтырга булдым. (Р.Т.) 11. Костин взводка таба борылды: - Атлардан төшәргә! (Г. Г.-й)

Күнегү 49. *Фигыльләрне табып, морфологик анализ ясагыз.*

1. Мунча якты. Улы иртәгә
Каралырга барасы.
Комиссия тикшерәчәк
Солдатлыкка ярасын.
«Яраклы!» дип кайтарырлар,
Шикләнми анысына,
Бүтән-үзгә бер күз белән
Карый ул баласына.
Малай дисәң – инде олы,
Егет дисәң – иртәрәк.
Шулай да җиткән вакыты
Өйдән чыгып китергә … (Р. Ф.)
2. Без батырлык эзләп яшәмибез,

батырлыкка ләкин без әзер –
кирәк булса, үлемебез белән
ныгытырбыз илне, бизәрбез!
Җәлилчерәк кебек!
Еллар аша
Үрнәкләре тора яктырып …
Ватан өчен үлү – безнең бурыч!
Батырлыктан туа
матурлык!.. (Р. Х.)

Күнегү 50. *Түбәндәге тамырлардан, тиешле ясагыч кушымча ялгап, фигыльләр ясагыз.*

Таш, эш, теш, уй, ярдәм, бер, дус, ара, зур, күп, аз, арзан, ак, яшә, оста, яңа, кыз, ачык, чын, кич, башка, нык, бай, дер, тыпыр, шатыр, пышыл, пыр.

Күнегү 51. *Фигыльләрне табып, аларның төрләрен әйтегез һәм тулы морфологик анализ ясагыз.*

Сабыйның рухы, ни бирсәң, шуны алучан, ни салсаң, шуны үзенең гомерлек хәзинәсе итеп урнаштыручан. Бирелгән нәрсәләр милли тәрбиягә нигез булсын өчен, иң элек үз анасының теле билгеле ысул белән йөрәгенә ярып салынырга тиеш: бала иң элек үз халкының хәрефләрен күрсен, үз авазын ишетсен; үз сүзләрен, үз җөмләләрен тикшерсен, кечкенә куллары иң элек үз хәрефләре белән үз ана теленең сүзләрен язсын. Һәр нәрсәне йотып алырга хәзер торган сабый йөрәгендә болар – каты мәгъдәнгә үткел корыч белән казып язылган кебек, мәңге бетмәслек тирән эз салачаклар, һәм шул беренче нигез булачак. Сабыйның гакылы икенче дәрәҗәдә тора, һәр нәрсәне ул тойгысы белән каршы ала. Аның тойгысына азык булачак нәрсәләр дә милли телнең асыл җәүһәрләре булсын: иң элек укыган әкиятләре үз телендә, үз баларыннан калган, үзенә таныш кәһарманнар хакында булсын; иң элек ишеткән зур вакыйгалары, олуг кәһарманнары, иң элек исемен күргән, телен ишеткән язучылары үз халкыннан булсын. (Г.И.)

## Теркәгечләр

Күнегү 52. *Теркәгечләрне табып, аларны тезүче һәм ияртүче төрләргә бүлегез. Алар нинди җөмлә кисәкләрен һәм нинди җөмләләрне бәйләп киләләр?*

1. Хәзер безнең җәмгыятьтә төрле милләт халыкларының арасы шулкадәр якынайды ки, болар арасында аралашу чарасы буларак рус телен куллану һәм милли телләргә интернациональ сүзләр, халыкара атамалар кертү табигый һәм зарури бер хәл булып алга килеп басты. Безнең телгә элегрәк кереп үзләшкән халыкара сүз һәм атамаларның телне никадәр баетулары турында әйтеп тормыйм, бу һәркемгә билгеле. Бу процесс хәзер дә дәвам итә. Әгәр без, мәсәлән, соңгы елларда бөтен дөнья телләрендә әйләнешкә кергән ракета, космос, телевидение кебек төшенчәләргә татарча сүзләр ясарга азапланып маташсак, бу һич акыллы эш булмас, бәлки милли телне ясалма рәвештә чикләү килеп чыгар иде. (Г.Б.)

2. Әгәр безнең телдә кирәкле сүз юк икән, шул ук телнең мөмкинлекләреннән чыгып, яңа сүз ясала. Инде алай да булмый икән, ул вакытта интернациональ яисә гомумән чит тел сүзе алына. Минемчә, бу – безнең әдәби телнең үсеш юлларын, аның тугандаш һәм күрше халыкларның телләре белән аралашып үсүен истә тотып эшләнгән бик дөрес кагыйдә. (Г.Б.)

Күнегү 53. *Теркәгечләрне табыгыз. Алар урынына нинди синоним теркәгечләр куеп булыр иде?*

1. Бу хәл Зиннәтне тетрәтеп җибәрде, ләкин Айсылу моны сизмәде. (Г.Б.) 2. Моны мин дә беләм, ләкин шулай да үз кандидатурамны тәкъдим иттем. (Я.Ч.) 3. Егет, кулларын угалап, винтовкасын иңбашына җайлабрак элде дә тагын да кызурак атларга тотынды. (Г.Б.) 4. Шәмси әллә илле чакрым, әллә артык та куйды. (Г.Б.) 5. Ул барды-барды да, гүя үзенең ничек болай ялгыз калуына гаҗәпләнгәндәй алдына-артына, як-ягына карады. 6. Ул чакта Стәрлегә поезд да, самолет та, автомашиналар да йөрми иде. (Р.И.) 7. Эзләп тә караганнар, әмма белүчеләр юк икән. (А.Ш.) 8. Авылдан ераклашканнан-

ераклаша барам, ә күңелем, җаным шул авылда, салкын өйдә, ятим балалар янында. (А.Ш.) 9. Тапкансың икән, югалтмаска, сүндермәскә, бәлки ничек кенә булса да, аны ялкын итеп дөрләтергә кирәк. (И.Н.) 10. … бу хәтәр утка очраклы килеп эләгүчеләр дә байтак, беришесе исә, ни эшләүләрен белеп бетермичә, гомуми хәрәкәткә буйсынып кына кулына корал алган … (С.Ш.) 11. Әллә гадел сүзләр тәэсир итте, әллә баштагы ярсу басыла төште, тик командирга кул күтәрүче табылмады. (С.Ш.)

## Кисәкчәләр

Күнегү 54. *Өзектән кисәкчәләрне табып, төркемчәләргә аерыгыз һәм мәгънәләрен күрсәтегез.*

Түбән һәм Югары Симеттән безнең алар нәкъ биш килен иде. Болар кадәр бер колония, бер коллектив булып яшәгән киленнәрне башкача белмим мин. Август ахыры. Кыр эшләре инде беткән, бәрәңге алганчы ниндидер бер ара вакыт бар. шул көннәрдә әни активлашып китә: аеруча бер дәрт белән авылдаш «килленнәр»гә йөри башлый. Күршеләр, план коралар, көнен билгелиләр. Берәр көн кала сәгатен үк билгелиләр. Әни пешеренә-төшеренә. Күчтәнәчкә ул төш пешерергә ярата иде. Күлмәк, яулык, аяк киемнәрен карый. Сандык төбеннән бик күп тишекле, бик күп вак тимер колаклы кара ботинкаларын ала. Ул ботинкалар бары тик Симеткә барганда гына киелә. Менә алар баш очларына төенчек утыртып, кыр казларыдай тезелешеп, Симет ягына таба юл алалар. Алардагы шатлык, алардагы күңел күтәренкелеге.

Күнегү 55. -мы, -ме *кисәкчәсенең функцияләрен күрсәтегез.*

1. Зинһар, нинди дә булса бер гәзитәгә берәр турында хәбәрме, мәкаләме яз… (Г.И.) 2. … атның башына җанчык ябамы, җаулык тагамы? (Д. с.) 3. Шәймәрдән. Синең кем икәнлегеңне белми бит ул? Белсәме, бусагасына якын китермәс. (А.Г.) 4. Хөрмәтулла. Бер ел үзем теләгәнчә яшәсәмме, аннары кайбер кешеләр белән сөйләшә белермен. (А.Г.) 5. Аннары инде

шагыйрьләрчә хисләнеп, сурәтләп сөйли башласаммы? (М.Р.) 6. Зөләйха. Кайтсын әле Закир үзе. Яптырып куймасаммы мин сине! (М.Ә.) 7. Яңгыр буласын сизепме, бал кортлары да ашыга. (М. Х.) 8. Яз килдеме, Ык таша. (М. Хәб.)

## Бәйлекләр

Күнегү 56. *Бәйлекләрне табыгыз. Алар нинди сүзләрне бәйлиләр – бергә язып алыгыз.*

…Тел өстендә уйлану – өзлексез дәвам итә торган акыл эше. Дөрес, бу әле һәр сүз, һәр җөмлә өстендә баш ватып утыру дигән сүз түгел. (Алай утыра башласаң, өч битлек хикәяне дә очлап чыга алмаска мөмкин). Әнә Туфан Миңнуллин әйтә, «телсез» язучы юк, булмый ул, ди. Әлбәттә, шулай. Мин дә үземне «телсез»ләрдән санамыйм, ләкин шуңа карамастан минем өчен язуның иң авыр өлеше «телгә» кайтып кала. Хикмәт нәрсәдә? Хикмәт шунда ки, әйтәсе һәм күрсәтәсе килгән бөтен нәрсә – фикер һәм хистән алып, төскә һәм искә (мәсәлән, чәчәк исенә) хәтле – үзенең иң дөрес, иң төгәл сүзен табарга тиеш. Язган чакта нәкъ менә шуны, ягъни әйтергә теләгәнең белән кәгазьгә төшкән сүзнең бер-берсенә ничек тә туры килүен өзлексез күзәтеп барырга мәҗбүр буласың да инде. Ләкин эш моның белән генә бетми бит әле, телнең һичшиксез, яхшы телнең, үзенә генә хас табигый агышы, аһәңе һәм ритмы да булырга тиеш – язганда шуны гел генә тоеп, чамалап бару да язучыдан шулай ук бик нык таләп ителә. Кыскасы, әдәбият ул – тел сәнгате, беренче сүзеннән алып соңгы ноктасына чаклы. Бәс шулай булгач, телнең әнә шул таләпләренә буйсынмаган, сүз эзләп, җөмлә төзәтеп газапланмаган язучы дөньяда бар микән?! Булмас, юктыр, «телсез» язучы булмаган шикелле, теле өчен борчылмаган язучының булуына да никтер ышанасы килми. (Ә. Еники. Язу – намус эше.)

Күнегү 57. *Бәйлекләрне табып, функцияләрен билгеләгез.*

1. – Себер ягында юк андый кәҗә сакаллары. Шуларына кадәр сагындырды. (Р.Т.) 2. Сәкинә. Кем көлә? Миндар.

Гөлүзәсенә кадәр көлә. (Ю.Ә.) 3. Шуны аңлапмы, Гөлчирәгә хәтле Сабирны калдырып китте. (М.М.) 4. Болын өстен әйткән дә юк, тау кырыйларына хәтле чуп-чуар. (Г.Б.) 5. Әхмәттән көнләшеп, юл буе үчекләп килгән Нимҗанга тикле телсез калды. (Г.Б.) 6. – Казан чаклы Казаннан килеп, нигә башта председательгә күренмәде?... (М. Хәб.) 7. ... ул кыз чынлыкта исә Чистай хәтле Чистайдан тик бер теләк белән – шагыйрь Габдулла Тукайны күрү теләге белән генә килгән. (Ф.Х.) 8. – Стан тикле станны хурладылар бит! (Х. Кәр.)

## Ымлыклар, аваз ияртемнәре

Күнегү 58. *Ымлыклар һәм аваз ияртемнәрен табыгыз.*

Ә чыршы усаклардан күп биек булса да, мондый гына җилне санга сукмады. Очлы башын алга-артка чайкаштырып борын эченнән генә гамьсез гүелдәп утыра бирде:

- Гү-ү... Гү-ү-ү...

Тагын бераздан карт имән уянды. Ул җилбәзәк усакларның юк-барга гауга күтәрүләрен ошатмады. Ябалдаш башын әкрен генә калкытып, йөнтәс кашлары астыннан «Җитәр сезгә, шытырдыклар»дигән кебек усал гына карап куйды да яңадан күзләрен йомды. Усаклар шунда ук: «Тс-с! Ш-ш-ш!» - дип, бер-берсен кисәтә башадылар.

Булатның йөрәге дөп-дөп тибәргә тотынды. Ул түземсезләнеп Карурман бабайның җыр башлавын көтә иде. (Г.С.)

Күнегү 59. *Аваз ияртемнәрен һәм аларга нигезләнеп ясалган сүзләрне табыгыз.*

1. Чыр-чу киләләр, көлешәләр, шайтанар! (Ә.Е.) 2. ... моңарчы бу залда беркем дә ишетмәгән бер көйнең, бер моңның ниндидер бер урынын тотып алды да, җырның сүзен әйткәндә, тамак белән, дөресрәге, йөрәк белән гөлдер-гөлдер китереп чирек секундлык кереш ясады. 3. ... ул елгачыклар бөтенесе дә юл алган, һәрберсе, чурлап аваз салып, Казанка елгасының мәһабәт салмак шавына кушылганнар иде. (М.М.) 4. ... колхоз председателе һәм Зөфәр шагыр-шогыр атлыйлар. (Є.Е.) 6. Менә

шул алдагы атта баручы кешеләрнең баш өсләрендә нидер җылык-җылык уйнаклап куйгалый. (Ә.Е.)
7. … хәтта башакларның бер-берсенә ышкылып кыштырдаулары ишетелә. (Ә.Е.)

**Учебное издание**

**Зарипова Г.Г.**
**Мирдиянова Б.М.**

# ТАТАРСКИЙ ЯЗЫК. КУЛЬТУРА РЕЧИ

УЧЕБНО-МЕТОДИЧЕКОЕ ПОСОБИЕ

Корректор Габдурахимова Т.М.
Худ.редактор Федорова Л.Г.

Сдано в набор 20.10.2013
Подписано в печать 28.11.2013
Бумага писчая. Гарнитура Таймс.
Усл.печ.л.3,75. Тираж 100.
Заказ №54.

НХТИ (филиал) ФГБОУ ВПО «КНИТУ»,
г. Нижнекамск, 423570, ул.30 лет Победы, д.5а.